Безнең балалар бакчасында  төрле яшьтәге балалар белән Россия символикасы, Татарстан символлары, флаг, герб белән танышу, ныгыту эшләре даими алып барыла.”Туган тел” көне һәр төркемдә матур күренешкә әйләнде. Аның матурлыгы, гүзәллеге балаларда  ярату хисләре тудырды.

Без кабатланмас тарихы, культурасы, милли йолалары, күренекле шәхесләре булган шәһәрдә яшибез. Без шуны истә тотып, балаларны үзебез яшәгән шәһәрнең тарихы белән таныштыру күзлегеннән "Казанның элекке һәм хәзерге тарихы турында" 6-7 яшьтәге балалар өчен программа төзедек. Рус телле тәрбиячеләре өчен бу программа рус телендә язылды. Ул балаларның яшь үзенчәлекләрен һәм белем биру өлкәләрен исәпкә алып эшләнде.

Программада "Казан- элеккеге һәм хәзерге шәһәр", "Республика символлары", "Милли киемнәр", "Габдулла Тукай", "Казан урамнары" "Шәһәр сулыклары", "Сабантуй бәйрәме", "Тутан якка экскурсия" кебек темалар яктыртыла. Материал сайлаганда балаларга аңлаешлы һәм кызыклы булуын истә тоттык; күрсәтмә материаллар тупладык, балалар үзләре актив катнашучылар булырлык чаралар эзләдек.

1) әти-әниләр белән берлектә “Минем яраткан шәһәрем” темасына фотокүргәзмә оештырдык;

2) Казан шәһәре куренеше тематикасына рәсемнәр тупладык, җырлар тыңладык;

5) Шәһәребез турында шигырьлер сайладык һәм өйрәндек;

4) "Минем шәһәрем" темасына рәсем конкурсы үткәрдек.

Балаларны татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, туган як тарихы белән таныштыруның иң нәтиҗәле юлларын ачыклау максатыннан, милли почмаклар оештырдык.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: патриотик тәрбия бирүне әхлак, экологик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясеннән аерып алып карарга ярамый. Алар комплексль рәвештә алып барылса гына, гражданлык хисләре тәрбияләүдә уңышка ирешеп була.

“Ватанны саклаучылар көне” темасына багышлап бакчабызда кичәләр оештыру бик җанлы рәвештә уза. Гадәттәгечә, әлеге бәйрәм алдыннан бакчада зур әзерлек эшләре алып барыла. Бу кичә әтиләргә, абыйларга, солдатларга һәм булачак Ватанны саклаучыларга багышланган уеннардан, өйрәнгән шигырләрдән, җыр- биюләрдән тора. Балалар һәм ата-аналар “малайлар”,

“батыр солдатлар” спорт ярышларында бик теләп катнашалар. Һичшиксез, мондый эш формалары балаларда үз иленә, аның традицияләренә карата горурлык һәм хөрмәт хисе тәрбияләми калмаячак.

23нче февраль, Җиңү бәйрәмнәре бакчабызда бик күркәм күренешкә әйләнде. Һәр төркем бу бәйрәмнәргә җитди әзерләнә.Тәрбияче белән берлектә стена газеталары чыгарыла. Зур кызыксыну белән тәрбияләнүчеләр тәрбиячеләр ярдәме белән яраткан әтиләре, бабайлары, өлкән абыйлары өчен төрле материаллардан бүләкләр ясыйлар.

Төрле эш материалларыннан кул эшләре күргәзмәләре оештырыла. Быел өлкән төркемнәрдә тәрбияләнүче балалар “Солдат хаты” конкурсында бик теләп катнаштылар. Бу бәйрәмнәрдә бакчабыз тәрбиячеләр, әти-әниләр тырышлыгы белән тулысынча бәйрәм төсен ала.

Бәйрәмгә кагылышлы атмосфера тудыру максатыннан балалар бакчасы бәйрәм атрибутикасы белән бизәлә. Төркемнәрдә һәм холлда “Ватанны саклаучылар”, “Безнең армия” газеталары, “Безнең әтиләр - солдаталар” фотогалереясы урнаштырыла.

Балалар белән хәрби җырлар өйрәнелә, хәрби шигырьләр сөйләнелә, танып-белү дәресләре уза, «Тынычлык», "Совет солдаты", "Ватан" темаларына рәсемнәр ясала. Бәйрәмгә ветераннарны хөрмәтләү йөзеннән әби - бабайларны чакыру күркәм гадәткә керде.

“Үлемсез полк” акциясендә катнашабыз. Һәр төркем бу бәйрәмнәрдә үзләренең тырышлыкларын күрсәтәләр.

Бу шөгыльләр барысы да буыннарның тарихи дәвамчанлыгын саклап калу, илебезнең тарихи үткәненә һәм хәзергесенә сакчыл мөнәсәбәт, Бөек Ватан сугышы вакытында әби- бабаларыбыз батырлыкларына хөрмәтле мөнәсәбәт тәрбияләү, үсеп килүче буынның рухи-әхлакый һәм патриотик сыйфатларын формалаштыру максатыннан чыгып үткәрелә. Үз иленең чын патриоты гына ата- аналары, бабалары калдырган кыйммәтләрне, гөреф – гадәтләрне һәм барлык мирасны яклаячак.

Бакчада тәрбияләнүче һәр бала кешеләр бәхете өчен гомерләрен биргән каһарманнарны, аларның исемнәре шәһәр, урам, мәйдан исемнәрендә мәңгеләштерелүе, алар хөрмәтенә һәйкәлләр куелуы турында яхшы белә. Бәйрәмгә багышланган чаралар бу көнне күңелле итеп кабул ителә, туган ил өчен горурлык хисе тудыра; балаларда Россия Армиясенә карата хөрмәт, Ватанга мәхәббәт тәрбияли; малайларны яклаучы булырга өйрәтә; балалар һәм өлкәннәр арасында хезмәттәшлекне тормышка ашыра.

Шулай ук бакчабызда “Җиңүгә бергә киләбез” акциясе узды. Бу акциядә тәрбиячеләр, ата-аналар бик теләп катнаштылар. Барлык җыелган товарлар (уенчыклар, киемнәр, ашау ризыклары) волонтерлар кулына тапшырылды. Бу чара безнең бердәмлегебез белән көчле булуыбызны күрсәтте. Хәрби операциядә катнашучылар үз гомерләрен куркыныч астына куеп илебез тынычлыгын саклыйлар. Шуңа күрә көчебездән килгәнчә ярдәм итү безнең төп бурычыбыз булып тора. Бу акциядә катнашучы һәркем солдатларга үзләренең теләкләрен, йөрәк җылысын җиткерде. Балалар белән үткәрелгән мондый чаралар аларның күңелләрендә патриотлык, Ватан алдында бурыч хисләре уята.

Ата-бабаларның тарихын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү аша туган җиргә горурлык һәм хөрмәт тәрбияләнә. Монда мөһим роль әкиятләргә карый, алар буыннан-буынга тапшырыла һәм яхшылыкка, дуслыкка, үзара ярдәмгә һәм тырышлыкка өйрәтә. Үзенчәлекле халык фольклоры-Ватанга мәхәббәт һәм балаларның патриотик үсешен формалаштыручы искиткеч материал. Бала дәүләт һәм халык бәйрәмнәре турында төшенчәгә ия булырга, аларда актив катнашырга тиеш. Шулай ук аларны башка халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм традицияләре белән таныштырырга, аларга карата дуслык мөнәсәбәтен формалаштырырга кирәк.

Бакчабыз балалары быел патриотик тәрбия темасына оештырылган “Татар малае”, “Идел буе варислары” конкурсында катнашып, финалга чыктылар.

Патриотизмның бер чагылышы –табигатькә мәхәббәт. Без табигать белән гармониядә яши белүче, әйләнә-тирә мөхиткә сакчыл караучы кеше формалаштырырга тиеш. Балада хайваннар, үсемлекләр дөньясына сакчыл караш, мәхәббәт тәрбияли алсак, без үз бурычыбызны үтәдек диеп әйтә алабыз. Паркларга, урманнарга баргач үзеңнән соң чүп калдыруның зур аянычларга китерүен бала аңлый. Яшел урманнар, үсемлек һәм хайваннарны саклау турында балалар әти-әниләре белән берлектә кечкенә китапчыклар эшлиләр, тәрбиячеләр белән квест уеннар уйныйлар.

Бакчабызда үткәрелә торган ”Көзне озату”, ”Нәүрүз , ”Әниләр көне” ,”Яңа ел” ,”8 Март” бәйрәмнәре дә әхлакый-патриотик тәрбия бирү максатыннан чыгып үткәрелә.

Безнең балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр ел саен төрле бакчада, район күләм, халыкара, республика конкурсларда катнашып киләләр. Балалар бакчалары данын яклау, катнашулары белән бик сөенәләр. Бу ярышларда алар өчен җан аткан, безгә ярдәм итүче ата-аналар һәрвакыт әзер.

Яшь буынга патриотик тәрбия бирү мәсьәләсе һәрвакыт актуальлеген югалтмый. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү проблемасы җәмгыять өчен иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Хәзерге вакытта патриотизм, гражданлык тәрбияләү -шактый авыр бурыч, аны хәл итү сабырлык таләп итә. Нәкъ менә патриотик тәрбия бала шәхесенең формалашуында, үз иленең гражданинын формалаштыруда бик мөһим нәрсә.

Бакчабызда балалар бик актив төрле күләм бәйгеләрдә катнашып призлы урыннар яулыйлар. Бакча данын яклый, аны башкаларга да күрсәтә алулары белән алар горурланалар. Чөнки нәкъ патриотик тәрбия бала шәхесенең формалашуында иң мөхим роль уйный.

Нәтиҗә ясап, әйтәсе килә: патриотик тәрбия бирүне әхлак, экологик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясеннән аерып алып карарга ярамый. Алар комплекслы рәвештә алып барылса гына, гражданлык хисләре тәрбияләүдә уңышка ирешеп була.

# СОВРЕМЕННЫЕ СТРАТЕГИИ ВЗАИМОДЕЙСТВИЯ РОДИТЕЛЕЙ И ПЕДАГОГОВ В ЦЕННОСТНОМ ВОСПИТАНИИ ОБУЧАЮЩИХСЯ

***Зайнуллина Т. Д.***
*магистрант 1 курса, Казанский (Приволжский) федеральный университет, Институт психологии и образования, г. Казань*
***Насибуллов Р.Р.***
*доцент к.п.н. Казанский федеральный университет, г. Казань*

Система образования XXI века переживает трансформацию, в центре которой находится личность обучающегося, его гармоничное интеллектуальное и духовно-нравственное развитие. В этом контексте ценностное воспитание, понимаемое как целенаправленный процесс усвоения и принятия общечеловеческих и социокультурных ценностей, приобретает первостепенное значение. Однако эффективность данного процесса невозможна без согласованных усилий двух ключевых институтов социализации – семьи и школы [3]. Современная социокультурная ситуация, характеризующаяся плюрализмом ценностей, информационной насыщенностью и зачастую размытостью нравственных ориентиров, диктует необходимость поиска новых, более продуктивных стратегий взаимодействия родителей и педагогов.

Традиционные формы работы с родителями зачастую носят монологичный и информационно-отчетный характер, что не способствует созданию подлинного партнерства [1]. Современный подход предполагает переход к стратегии педагогики сотрудничества, где родители и педагоги – равноправные субъекты воспитательного процесса, объединенные общей целью.

Можно выделить несколько ключевых современных стратегий взаимодействия:

1. Благотворительные акции, театральные постановки на нравственную тематику, создание семейных музеев или «Книг памяти»: подобные

события создают эмоционально насыщенную среду, в которой ценности усваиваются наиболее прочно.

2. Родительские клубы: встречи в формате «круглого стола», где обсуждаются конкретные проблемы воспитания [3].
3. Тренинги детско-родительских отношений: позволяющие на практике отработать модели поведения, основанные на взаимном уважении и диалоге.
4. Информационно-диалоговая стратегия в цифровой среде: тематический блог класса или школы, где размещаются не только новости, но и статьи, обзоры фильмов и книг, инициирующие обсуждение этических дилемм.
5. Стратегия «Родители как ресурс». Родители-профессионалы могут проводить мастер-классы, рассказывая о ценностях своей профессии. Бабушки и дедушки становятся незаменимыми участниками проектов, связанных с семейными традициями и исторической памятью. Это не только обогащает учебно-воспитательный процесс, но и повышает статус семьи в глазах ребенка.

Таким образом, современные стратегии взаимодействия родителей и педагогов в сфере ценностного воспитания движутся в сторону интерактивности, диалогичности и проектной деятельности. Ключевым условием их успешности является отказ от позиции взаимных претензий и переход к отношениям ответственного партнерства [2]. Только объединив профессиональный потенциал педагогов и уникальный воспитательный ресурс семьи, можно сформировать у подрастающего поколения целостную и устойчивую систему ценностей, способную стать надежным ориентиром в сложном современном мире.

## Литература


1. Безюлева, Г. В. Воспитательный потенциал семьи и школы в формировании ценностных ориентаций подростков / Г. В. Безюлева // Педагогика. – 2020. – № 4. – С. 45-52.

2. Воронцов, А. В. Сетевое взаимодействие семьи и школы в духовно-нравственном воспитании: новые вызовы и решения / А. В. Воронцов // Народное образование. – 2021. – № 5. – С. 112-118.
3. Метлик, И. В. Ценностные ориентации школьников и их формирование в совместной деятельности семьи и образовательной организации / И. В. Метлик // Воспитание школьников. – 2022. – № 3. – С. 15-24.

## ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

***АрсаеваЛ.Р.***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*
*«Хәкимов Д.Г исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең*
*башлангыч класслар укытучысы,*
***Потехина Л.А.***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*
*«Хәкимов Д.Г исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең*
*инглиз теле укытучысы.*

21 гасыр – компьютерлаштыру, инновацияләр, яңа технологияләр гасыры. Әмма тәрбия проблемасы әлеге этапта иң мөһим проблемаларның берсе булып кала бирә.

Яшь буынны патриотик рухта тәрбияләү белем бирү учреждениеләренең укыту программасына кертелгән мөһим юнәлешләреннән берсе. Чөнки кешелекнең киләчәге, Ватан язмышы, гаилә бәхете киләчәктә гражданин булачак нәни баланың бүген нинди тәрбия алуына бәйле.

Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү.

Патриотик тәрбия дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр, Ватанның лаеклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Патриотлык- үз иленә, туган җиренә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәниятькә мәхәббәт ул.

Безнең заманда патриотлык проблемасы-җәмгыятьнең актуаль һәм җитди проблемаларының берсе. Без Хәтер эстафетасын тапшырырга, үсеп килүче буынга җиңү яулаган совет кешеләренең батырлыгының бөеклеген һәм фидакарьлеген күрсәтергә тиеш. Балаларда патриотлык тәрбияләп, без рухи-әхлакый сыйфатлар да тәрбиялибез. Болар барысы да үзара бәйле.

Чыгышларының берсендә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин: «Без киләчәгебезне ныклы нигездә төзергә тиеш. Һәм мондый фундамент-ул патриотлык» диде. Патриотлык темасы яшь кеше өчен дә, урта яшьтәге һәм өлкән яшьтәге кешеләр өчен дә бертигез әһәмиятле.

Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә төп рольне укытучы үти. Укытучы – ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча, укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә, шәхес тәрбияләүче дә. Ә шәхес – җәмгыятебезнең җимеше. Җимешне өлгертер өчен күпме вакыт һәм көч кирәк: җирен йомшартып орлык чәчәргә, кибәргә бирмичә суын сибеп торырга. Заман технологияләре никадәр алга китмәсен, әмма барыбер укучыга рухи тәрбияне әти-әниләрдән тыш, укытучы бирә.

Бүгенге көндә мәктәпнең төп бурычы – Кеше һәм гражданин тәрбияләү. Балада үз «мин»ен тәрбияләми торып, без югары максатка ирешә алмыйбыз. Шуңа күрә иң беренче чиратта һәр балага шәхес итеп карау кирәк. Без – укытучылар патриотик тәрбия бирүдә түбәндәге юнәлешләргә басым ясыйбыз:

- туган ягыбыз, районыбыз, авылыбыз тарихы, мәдәнияте турында мәгълүмат бирү;

-туган як табигатенә карата хөрмәт, экологик тәрбия бирү;

-якташ язучылар, сәнгать кешеләре белән очрашулар үткәрү;

-халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре, әби-бабайларыбызның йолалары белән якыннан танышу;

- хезмәт, сугыш ветераннары, солдатларыбыз белән очрашулар;

-районыбыздагы музейларга экскурсия оештыру;

- эти – әниләр белән берлектә бәйрәмнәр, спорт ярышлары, кичәләр үткәрү үткәрү;

төрле патриотик конкурсларда актив катнашу.

Башлангыч сыйныфлар белән эшләгәнгә күрә патриотик тәрбияне без матурлык аша алып барудан башларга тырышабыз. Әйләнә-тирәдәге тормышның матурлыгы бала аңына ничек үтеп керсә, якыннарының намуслылыгы, табигатьнең, Туган җиренең гүзәллеге аның күңелендә шундый ук югалмас эз калдырачак. Башлангыч сыйныфларда патриотик тәрбия кече Ватанны өйрәнү, аның белән горурлану хисләре аша тәрбияләнә башларга тиеш.

Патриотик тәрбия бирүдә укытучыга туган төбәгебезнең табигате дә ярдәмгә килә. Чөнки Ватанның тарихы, халыкның кылган гамәлләре табигать белән тыгыз элемтәдә. Табигатьтәге матурлыкны кеше күңел көзгесе аша үткәреп үзенең кул эшләрендә чагылдыра.

Безнең төп бурыч - үзебезнең туган җиребездәге могҗизаларны күрергә өйрәтү. Бала туган җиренең табигатен, халкын, тарихын, мәдәниятен, рухи хәзинәсен белгәндә генә, анда иле өчен горурлык хисе уяначак.

Мәктәбебездә туган як табигате темасына төрле рәсем, инша язу конкурслары үткәрәбез. Иҗади эшләр башкарабыз. Ел әйләнәсе туган ягыбыздагы кошларны күзәтәбез. Җылы якларга китүче, кайтучы кошлар турында белемнәребезне туплыйбыз. Кышын «Кошларга җимлек», язын «Сыерчык оялары» конкурсларында бик теләп катнашабыз. Кошлар да безнең туган ягыбызга ямь бирүчеләр, матурлыкка өйрәтүчеләр.

Якташ язучылар, сәнгать кешеләре белән очрашуларда укучылар актив катнашалар. Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов укуларында катнашып призлы урыннар алалар.

2025 ел - безнең барыбыз өчен дә үзенчәлекле ел. Без Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын, илдә һәм республикада Ватанны саклаучылар елын билгеләп үтәбез.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан – ел ераклаша бара. Безнең туган авылыбыз да бу кайгы – хәсрәттән читтә калмады. Бу дәһшәтле елларда туган авылыбыз ниләр кичерде икән? Менә шушы сорау безне һәрвакыт уйланырга мәҗбүр итә.

Сугыш еллары елдан – ел артта калганга, әбиләребез – бабаларыбыз сирәгәя һәм олыгая барганга, безнең буын бу хакта белмәгәнгә күрә шушы турыда материал туплап эзләнү-тикшеренү эше үткәрдек,альбом ясадык. Ил тарихында, халык язмышында Әфган, Чечен сугышлары да тирән яра кал дырдылар.

Мәктәбебездә укыган, шушы сугышларда катнашкан укучылар белән очрашулар үткәрелә. Кызганыч,авылыбызда бер генә сугыш һәм тыл ветераны да юк. Укучылар белән без «Өлкәннәр көне»нә, «Җиңү бәйрәме»нә багышланган открыткалар ясап өлкәннәрне, сугыш чоры балаларын котлыйбыз. «Георгий тасмасы», «Үлемсез полк», «Ветеран янәшәдә яши» һәм башка бик күп акцияләр дә бездән башка узмый.

Хәзерге көндә Украинадагы махсус хәрби операциядә дә катнашучы солдатларыбызны онытмыйбыз. Аларга һәрдаим ярдәм итеп торабыз. «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз» акциясендә укучылар, әти-әниләр бик теләп катнашалар. Аларга хатлар язып торабыз.Авылдаш егетләр белән матур очрашулар үткәрәбез. Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә, абыйларыбызга багышлап уздырылган Батырлык дәресләре үткәрәбез.Аңа әзерләнгәндә геройларыбызның тормыш юлын өйрәнәбез, әти-әниләре белән очрашабыз. «Окоп шәмнәре»н дә укучылар бик теләп ясыйлар.

Мәктәбебездә бик бай этнография музее эшләп килә. Музей туган ягыбызга караган күмәк хуҗалыклар, мәктәп, мәдәният учаклары, җирлекнең күренекле кешеләре тарихын тирәнтен өйрәнү максатыннан 1994 нче елда оеша. Музейга 1980 нче елдан ук тарихи экспонатлар җыела башлый. Хәзерге көндә анда 600 дән артык тарихи-мәдәни мирас тупланган.

Андагы мәгълүмат баланы рухи яктан гына түгел, тәрбия, патриотик яктан бик ныгыта, күренекле шәхесләргә горурлык хисе уята.

Туган ил тарихының һәрнәрсәгә, һәркемгә, шул исәптән үзләре яшәгән гаиләгә дә, кагылышлы булуын аңлату, төшендерү кирәк. Һәр кеше үзенең җиде буын бабасын белергә тиеш, диләр.

Иң беренче итеп, әңгәмәләр үткәрәбез, «Минем гаиләм» темасына иншалар язып карыйбыз. Аннары әби-бабаларыбызны барлау ниятеннән әти-әниләр белән берлектә шәҗәрә төзеп карыйбыз. Гаилә шәҗәрәсен төзү гаилә әгъзалары белән ныклы элемтә урнаштырырга мөмкинлек бирә. «Минем шәҗәрәм» укучылар республикакүләм конкурсында катнашып 3 нче дәрәҗә дипломга лаек булды

Хәзерге шартларда туган илгә мәхәббәт тәрбияләү җиңел эш түгел. Ватанпәрвәрлек ул барлык гражданнар да, кемнең - кем булуына карамыйча, илгә файда китерү өчен тырышып эшләгән җәмгыятьтә генә була ала.. Балалар күңелендә өмет, киләчәкнең матур булуына ышаныч уяту - укытучының төп вазифасының берсе.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Ахметшина Г. Военно-патриотическое воспитание старших школьников/Г. Ахметшина // Мәгариф.- 2013.- №9.- Б.66-68.
2. Әхәт Садриев.Патриотлар тәрбиялибез.» Мәгариф» журналы №3, 2010.
3. Гатауллин Р. Патриотик тәрбиягә – игътибар/ Р. Гатауллин // Мәгариф.- 2005.- №5.- Б.57.
4. Камаева Р.Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр/ Р. Камаева // Мәгариф.-2014.-№11.- Б.16-21.
5. Хәйруллин Р. Патриотлар тәрбиялибез/ Хәйруллин Р.// Мәгариф.- 2008.- №5.- Б.47-48.
6. Хуҗи Мәхмүтов. Ватан барыннан да газиз. «Мәгариф» журналы, №2,2003.
7. Шамил Җәләлиев. Патриотизм нәрсә ул? «Мәгариф» журналы,10, 2002.

## ГАИЛӘБЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ

***Рәхмәтуллина А.Р.***
*Татарстан Республикасы Арча районы "Д.Г.Хәкимов исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе*
***Гыйбадуллина З.Ш.***
*Татарстан Республикасы Арча районы "Д.Г.Хәкимов исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе"*

Туган авылыбыз Мөндеш матур табигате белән данлыклы. Нарат, чыршы, каен агачлыклары авылыбызны төрле яктан ышыклап торалар. Болыннарыбызда матур чәчәкләр, авызда эреп китә торган җир җиләкләре, каен җиләкләре үсә. Челтерәп аккан чишмәләр Ия инешенә кушылып шул болыннарны сугаралар. Ия инешендә эреле – ваклы балыклар, сүүсемнәр күп. Инешкә яз көне кыр үрдәкләре кайта. Соңгы елларда су буенда челәннәр дә барлыкка килде. Авылыбыз читендә урнашкан Алма бакчасы яз көне ап-ак чәчәккә күмелә. Җәй көне бу бакча авылыбыз халкын мул уңышы белән сөендерә. Халык бирегә алма, гөлҗимеш, карлыган, кура җиләге, җир җиләге, гөмбә җыярга килә. Авылыбыз бай тарихы, төзек матур йортлары белән аерылып тора. Чөнки авыл халкы хезмәт сөючән, тырыш, бердәм. Авылыбызның һәр кешесе турында мактап, озак итеп сөйләп булыр иде.

Мәктәп укучысының төп вакыты гаджетларда узу сәбәпле, балаларга белем һәм тәрбия бирүдә "бушлык" барлыкка килү берәү өчен дә сер дә, яңалык та түгел. Баланың фикерләве, сөйләм теле, хәтере өчен көрәш нәкъ тә менә укытучылар җилкәсенә төшә. Әлбәттә, методика нигезендә педагогика фәннәре докторы, профессор, республикабызның атказанган укытучысы Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов теориясе. Ул да бит үзенең "Тәрбия дәресләре" китабында укучыларга патриотик, хезмәт, әхлак һәм гаилә тәрбиясе бирүнең мөһимлеген ассызыклый. Бу тәрбия элементлары, балаларыбызның күңеленә үтеп керү, бүгенге көндә бигрәк тә кирәк. Әлбәттә, халык педагогикасы, исемнәре тарихка кереп калган педагогларыбызның хезмәтләре дә безгә укыту процессын дөрес оештырыр өчен нык ярдәм итәләр.

2025 нче ел Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителгәнлектән, мәктәптә үткәрелүче чараларның да күбесе шул темага бәйләп алып барылды. Һәр укучы катнаша алырлык, гаиләдә өлкәннәр һәм балалар арасында күмәк эш китереп чыгарырлык күп кенә чаралар арасында, берсе бигрәк тә игътибарга лаеклы булды. Тәрбиянең барлык принципларын да үз эченә алган бу чара “Гаиләбезнең горурлыгы” дип аталды. Һәр гаиләнең – үз герое бар: һөнәрчеләр, Бөек Ватан сугышы геройлары, Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылар, волонтерлар, хезмәт батырлары – берәү дә игътибардан читтә калмады. Мәктәбебез укытучылары да бу эштән читтә калмады.

Проектларыбызның берсен сезнең игътибарыгызга тәгъдим итәбез. Чөнки ул безнең гаиләбез белән бәйле. Гаиләбезнең нәселе борынгы, данлыклы, мактаулы.

Дәү әтиебезнең нәселен Гыйбадуллалар нәселе, диләр. Ерак бабабыз Гыйбадулла булган. Сөнгатулла – аның онычы. Гыйбадуллин Сөнгатулла 1897 нче елда туа. Балачагы авыр елларга туры килгән аның. Ачлыкны да, авыр сугыш елларын да күрә ул. Яшьтән үк хезмәт сөючән булып үсә. Ул бертуган энесе Каюм белән җиздән комган, самовар, кыңгырау, шөлдерләр ясаган. Җиз самоварларны никельләп тә куйганнар. Бу һөнәрчеләр сәгать, тегү машинасы, сепараторлар да ремонтлаганнар. Ясаган әйберләре базарга да илтеп сатканнар, сатып алучылар өйләреннән дә алып киткәннәр. Авылдашларыбыз аларның юмарт, ярдәмчел булулары турында гел искә алалар. Берәүнең дә үтенечен кире какмыйлар. Авыр хәлдә яшәүчеләргә, яңа гаилә корып яшәүчеләргә ярдәм йөзеннән аларга йорт кирәк-яракларын бушка да ясап биргәннәр. Икесе дә өйләнәләр. Гаилә ишле була. Ике гаилә дә бертөрле әйбер ясаганлыктан, сату-алуда кыенлыклар барлыкка килә. Туганнар мәсьәләне хәл итү юлын эзли башлыйлар, һәм табалар да. Гыйбадуллин Каюм Яңа Кырлай авылына күченеп, шул авылда һөнәрчелек белән шөгыльләнүен дәвам итә. Ә Сөнгатулла бабай Мөндеш авылында гомер кичерә.

Сөнгатулла бабайның аерым эш бүлмәсе дә була. Бүлмәдә һәрвакыт чисталык һәм тәртип, һәр эш коралы – үз урынында. Куркынычсызлык кагыйдәләрен искә алыптырмы, бабайны борчымас өчендерме – балаларга анда керү рөхсәт ителми иде. Ләкин мондагы зур станоклар, бабайның киеп эшли торган калын, зур алъяпкычы әле дә истә.

Бакча эшен дә бик яратып эшли бабабыз. Яшелчә генә түгел, җиләк-җимешләр дә үстерәләр. Бакчаларында бик күп алма агачлары үскән. Авылдагы иң тәмле алмалар – бабай бакчасында үскән дип сөйлиләр.

Аз сүзле, уңган егет Бибиҗаман әби белән гаилә кора. Алар 4 ул, 2 кыз үстерәләр. Кызлар, кияүгә чыгып, төп йорттан чыгып китәләр. Дәү әтиебез – Әмин, ул механик булып эшләгән. Машиналар, мотоцикл, тракторларны оста ремонтлавы, транспортның тавышыннан ук кайсы җире ватык икәнлеген белүе турында бүген дә сокланып сөйлиләр. Мидхәт абый оста эретеп ябыштыручы була. Сепараторларны ремонтлау өчен аның янына күрше авыллардан да киләләр.

Бервакыт Сөнгатулла бабайларга бер урыс кешесе килә. Бик гозерләнеп кыңгырау ясап бирүен сорый. Ул кеше эш барышын да карап тора, күпме бакыр, цинк, җиз, кургаш кушып ясаганын күзәтә. Күпмедер вакыт үткәч, Сөнгатулла бабай базарга сату белән килә. Шунда ул теге кешенең кыңгыраулар сатып торганын күрә. Шуннан соң Сөнгатулла бабай улларына болай ди: “Үзең белгәнне кешегә өйрәтмә. Алар синнән дә остарак булып, син эшсез калырга мөмкинсең”, -ди.

Сөнгатулла бабай Бөек Ватан сугышында да катнаша. Аның исеме “Память народа” порталына да кертелгән. Ул еллар турында сөйләргә яратмаган ул. Үзенең яраткан һөнәрен анда да онытмый ул. Ә кайтканда – капчыгында тимер – томырлар һәм тегү машинасының каркасы була. Соңрак ул шушылардан тегү машинасы ясый. Бүгенге көндә ул тегү машинасы бездә саклана. “Зингер” дигән бу машина әле дә кулланышта.

Бабай – кадер-хөрмәттә, озын-озак яши. Гомеренең ахыргы елында гына авырып, урын-җир өстенә ята. 1983 нче елда вафат була.

Бүгенге көндә, Сөнгатулла бабай яшәгән төп нигездә, аның оныгы Фаил абый яши. Ул, этисе Мидхәт абый кебек, оста эретеп ябыштыручы. Фаил абый заман белән бергә атлый. Ул тиз арада калайдан тәрәзә йөзлекләре ясарга өйрәнеп, авылыбыздагы бик күп йортларның тәрәзәләрен матур бизәкләр белән бизи. Мидхәт абыйның тагын бер улы – Вәкил. Аларның капка төбеннән кеше өзелми. Чөнки ул күрше-тирә авылларга гына түгел, районнарга да билгеле булган сыер саву аппаратларын көйләүче һәм ремонтлаучы.

Сөнгатулла бабайның оныгы Фәргыя - минем әнием дә аның эшен дәвам иткән дисәк була. Ул гомере буе “Мөндеш сельхозтехникасы”нда склад мөдире булып эшли. Машина, трактор, комбайн өчен кирәкле һәр детальнең исемен, кулланышын белә. Мотоцикл да йөрткән әле ул, аны үзе ремонтлаган да!

Сөнгатулла бабайның тагын бер оныгы – Гыйбадуллин Илнар. Ул Арча районы Түбән Мәтәскә авылында яши. Бар эш тә кулыннан килә. Берничә ел элек шиномонтаж ачты. Бүгенге көндә, машина белән бәйле күп проблемеларны хәл итү өчен, күрше-тирә авыл халкы нәкъ менә аның янына килә.

Бабабыз турында онытмыйбыз. Өлкән апаларыбыз гына түгел, күршедәге әбиләр дә аны гел яхшы яктан искә алалар. Рәхмәтуллина Алсу аның турында сөйләп, “Яңа гасыр” телеканалында чыгыш та ясады.

Без Сөнгатулла бабабызның оныгы булуыбыз белән чиксез горурланабыз. Аның кебек һөнәрче булу кулдан килмәсә дә, укучылар белән төрле чаралар үткәргәндә һөнәрчелек элементларын кулланырга тырышабыз. Мәсәлән, “Чишмә бизәү”, “Милли киемнәрне бизәү” проектлары укучыларыбыз күңеленә хуш килде. Әйдәгез, бүген дә шундый эшне башкарып алыйк әле. (Мастер класс: читек, түбәтәй бизәү).

Киләчәк буыннар да гаиләләренең геройларын белеп үссеннәр, искә алсыннар өчен тырышабыз.Бу безнең бурычыбыз.

Әдәбият:

1. Ә.Н.Хуҗиәхмәтов “Тәрбия дәресләре”. Педагогик уку йортлары өчен ярдәмлек. Казан, 1988 нче ел. 424 бит.
2. “Память народа” интернет сайты.

# МАТУР ӘДӘБИЯТ АША ТУГАН ЯКНЫҢ ТАБИГАТЕН ӨЙРӘНҮ

***Гибадуллина И.Г.***
*башлангыч сыйныф укытучысы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Д.Г.Хәкимов исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
***Гайнетдинова А.А.***
*башлангыч сыйныф укытучысы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Д.Г.Хәкимов исемендәге Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы ул. Табигатьне ярата, аның матурлыгын тоя, күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый. “Табигатьне ярат, чисталыкны сакла!” Бу шигарь гади генә сүз түгел, әлеге сүзләр безнең Арчалыларның тормыш кодексы: 21 гасырның 1нче кагыйдәсе дә әле. Әйе, табигать белән кеше бербөтен булып яшәргә тиеш. Моның өчен без барыбыз да үзебезнең туган авыл, туган ягыбызны, андагы чишмә-күлләребезне, болын-тугайларыбызны, аларның барлыкка килү юллары турында өйрәнергә тиешбез. Табигатебез- безнең уртак йортыбыз.Аны кечкенәдән үк ярата, аның матурлыгын тоя, күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый. Бары тик әхлаклы, намуслы, чын кеше булыр.

Безнең әби-бабаларыбыз табигать байлыкларыннан бик сак файдаланганнар. Җәнлек балаларын ауламаганнар, кечкенә балыкларны да суга кире җибәргәннәр, яшь агачларны кисмәгәннәр.

Мең еллар дәвамында халыкның аңына сеңгән, аның яшәешенең үзәген тәшкил иткән табигатькә сакчыл караш буыннан буынга күчеп килгән. Баласын табигатьне саклаучы, яклаучы, хөрмәт итүче итеп тәрбияләү һәрбер әти-әнинең, әби-бабайның изге бурычы саналган. Мондый тәрбия төрле йола,

риваять, җыр, бәет аша бирелгән. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләүдә, халык педагогикасы белән беррәттән, матур әдәбиятның да роле зур.

Тәрбия сәгатьләрендә файдаланылган әсәрләрдән берничә өзек китерәм.

Умырзаялар уянды

Тургайларның җырына.

Ак күлмәкле каен-кызлар

Төренде яз нурына.

(К. Тәхау)

“... Туган җир, дисәм, беренче мәртәбә кояш нурында коенуым искә төшә, туган җир, дисәм, салават күперенең җиде төсе җитмеш төскә кереп балкый башлый, туган җир, дисәм, җилләр телен аңлыйм мин, тын гына очкан кар бөртекләренең үзара сөйләшкәннәрен ишетәм...” (Ф. Шәфигуллин. “Туган җир – туган ана”)

Кеше күңелен табигатькә якынайта торган искиткеч сүзләр. Сер түгел, кайбер балалар әдәби әсәрләр укыганда табигать матурлыгын, аның белән кешеләр арасында барган үзара сөйләшүләрне тасвирлаган өзекләрне укымыйча калдыралар яки игътибар белән укымыйлар. Мин укучыларга шундый тасвирлауларны ашыкмыйча, берничә тапкыр укып чыгарга һәм бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп, эчтән кабатлап чыгарга киңәш итәм һәм өйдә рәсемен ясап килергә тәкъдим итәм. Икенче дәрестә укылган өзекләр һәм рәсемнәр буенча нәтиҗә ясыйбыз: “Табигать ни чаклы көчле булса, шулкадәр үк самими һәм безнең тарафтан яклауга, саклауга мохтаҗ икән!”

Экологик тәрбия бирү башлангыч сыйныфларда барлык фәннәрдән дә алып барыла. Мәсәлән, әйләнә-тирә дөнья дәресләре тере һәм терек булмаган табигатьтәге күренеш һәм процесслар турында белемнәр тупларга булышлык итә; балаларда туган як табигатенә мәхәббәт хисе, табигатьне саклау күнекмәләре тәрбияли.

Әдәби уку һәм сыйныфтан тыш уку дәресләрендә балалар табигать белеме дәресләрендә алган белемнәрен туган як турында шигырь һәм хикәяләр уку юлы белән тулыландыралар.

Татар балалар язучылары арасында табигать темасына мөрәҗәгать иткәннәре байтак. Гарәфи Хәсәнов иҗаты бу өлкәдә аерым урын алып тора.

Язучы үзенең хикәяләрендә туган як табигатен, аңа хас булган күренешләрне, үзгәрешләрне сурәтли. Кайсы ел фасылы турында гына язмасын, авторның туган як табигатен чын күңелдән сөюен, күзгә күренмәс үзлекләрен җаны белән сиземләвен тоясың.

Г. Хәсәнов хикәяләрендә балаларга таныш кош-корт һәм хайваннарның моңарчы игътибар ителмәгән сыйфатлары зур осталык белән сурәтләнә. Язучының шагыйрәнә күңеленә торнаның гади генә тавышы да, туган якны яратып, “монда торрыйк, монда оя коррыйк” дип әйткән төсле тоела. Язучының хикәяләрен укып, башлангыч сыйныф укучылары туган як табигате турында күп мәгълүмат туплыйлар, аны яратырга һәм сакларга өйрәнәләр. Ул белемнәрнең күбесе өлкәннәр өчен дә яңалык булырлык. Мәсәлән, имән агачы турында укучылар күп беләләр, әмма аның илле яшьтән чәчәк ата башлап, өч йөз яшьтә генә туктавы, меңәр ел яшәп, бал бирүе укучылар өчен гаять кызыклы.

3 нче сыйныфта без укучылар белән Нур Әхмәдиевның “Чишмәгә суга барам” шигырен укыганнан соң үзебезнең авылыбыздагы чишмәләргә дә сәяхәт кылдык, чөнки безнең Мөндеш авылы да чишмәләргә бай. Авылыбыздагы һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы, үз юлы бар.Челтер-челтер аккан чишмәләр кемнәрне генә сокландырмый да, кемнәрне генә сихерләми икән?! Чишмәне халык изге урын дип исәпли. Чит җирләрдә яшәүче авылдашларыбыз, туган якларына кайткач, иң беренче чишмә янына баралар. Чөнки Туган ил, туган нигез, туган авыл нәкъ менә шул чишмә буйларыннан башлана да инде.

Литература:

1. Хәсәнов Г. Елның дүрт фасылы. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.-75с.
2. Хәсәнов Г.  Җир - ул уртак йортыбыз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.-63с.

## ФИЛОЛОГИЯ ЯЗЫКОЗНАНИЯ ПРИ ИЗУЧЕНИИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В ДЕТСКОМ САДУ НЕПОСРЕДСТВЕННО ЧЕРЕЗ ТЕАТРАЛЬНОЕ И МУЗЫКАЛЬНОЕ ИСКУССТВО

***Валиуллина Г.Р.***
*педагог-воспитатель МАДОУ «Детский сад №293», г.Казань*
***Пантелеева Ж. А.***
*педагог-воспитатель МАДОУ «Детский сад №293», г.Казань*

В данной статье хотим рассказать о значении филологии языкознания при изучении татарского языка в детском саду непосредственно через театральное и музыкальное искусство. Мы поделимся практическим опытом проведения разнообразных форм работы, направленных на формирование любви к родному языку и культуре через интеграцию музыки и искусства.

Наше время требует от нас особого внимания к сохранению культурного наследия. Изучение родного языка и приобщение к музыке — важные шаги на пути к пониманию своей идентичности и формированию чувства патриотизма. Именно поэтому в нашем детском саду мы стремимся интегрировать творческий подход в обучении татарскому языку и музыкальной культуре.

Вопрос воспитания и обучения детей младшего возраста имеет особую значимость, поскольку именно этот период является определяющим этапом формирования личности ребенка. Изучение родного языка способствует развитию когнитивных способностей дошкольников, обогащению их эмоционально-чувственного опыта и приобщению к национальной культуре. Особую роль играют методы театрального искусства и музыки, которые помогают детям лучше усвоить родную речь, расширить кругозор и развить творческое мышление. https://disk.yandex.ru/i/fiOOTwsYhLpuGQ

Наша работа была направлена на исследование возможностей интеграции театра и музыки в образовательный процесс для эффективного

изучения татарского языка в детском саду. Важнейшую роль в данном процессе играют идеи татарских просветителей, которые смогли внести значимый вклад в развитие филологии и методики преподавания родных языков. Особое внимание уделялось созданию учебных пособий, дидактическим играм, стихам и песням, предназначенным специально для детсадовского возраста. Например, творчество Габдуллы Тукая включало народные мотивы, богатые образы природы, доступный язык и понятные сюжетные линии, идеально подходящие для восприятия маленькими детьми.

Интеграция театра и музыки на занятиях татарским языком положительно влияет на формирование языковой компетенции и культурного самосознания детей старших групп детского сада. Для достижения цели были использованы следующие исследовательские методы:

Анализ теоретической литературы по вопросам воспитания и образования детей дошкольного возраста.

Метод наблюдения за процессом обучения и поведения детей в ходе театральных и музыкальных мероприятий.

Практическое значение нашей работы заключается в разработке рекомендаций по совершенствованию образовательного процесса в дошкольных учреждениях, направленных на воспитание патриотизма и любви к своему народу через активное использование элементов народного творчества, традиций и обычаев.

Дети, живущие в многонациональных регионах, сталкиваются с необходимостью освоения двух и более языков одновременно. Это создает особые трудности для педагогов, стремящихся сохранить родной язык среди подрастающего поколения. Одним из наиболее эффективных способов сохранения и передачи национальных ценностей является организация игровых форм взаимодействия детей с родным языком. Поэтому мы не оставили в стороне тему народных игр. Народные игры имеют многовековую историю. Они сохранились и дошли до наших дней, передаваясь из поколения в поколение, вобрав в себя лучшие народные традиции воспитания физически

здорового, любознательного, творческого и жизнерадостного человека. Мы создали свою видео-картотеку народных игр: «Әтәчкәй», «Читек», «Самавар» уеннары https://disk.yandex.ru/i/umK2XDP_1O1DcA https://disk.yandex.ru/i/CmVQSFGgauvtcw https://disk.yandex.ru/i/h9Be58YuwPWe1g .

Для поддержания интереса детей к обучению мы стараемся создавать условия, в которых каждый ребёнок чувствует себя важным участником общего дела. Например, на одном из занятий мы предложили детям придумать собственные варианты завершения известных сказок. Такое задание позволило ребятам проявить фантазию и креативность, а также укрепить уверенность в своих силах. После обсуждения и отбора лучших вариантов мы записали аудиосказки, сняли свои мультфильмы, где дети озвучивали персонажей на татарском языке (мультфильмы: «Алмагачкай» https://disk.yandex.ru/i/s34cTTuhPqiJXw , «Шүрәле һәм чәк-чәк сере» https://disk.yandex.ru/i/nL6g4YiG9f278w ) Эта работа стала настоящей творческой лабораторией, где рождались идеи и формировались первые навыки публичных выступлений. Театральные постановки позволяют детям почувствовать себя участниками исторических событий, героев народных сказок и легенд, тем самым погружаясь в мир родного языка и культуры.

Музыкальные произведения также способствуют формированию правильного произношения звуков, расширяют активный словарь детей, развивают чувство ритма и мелодии, формируют музыкальный вкус и эстетический интерес к традициям своего народа. Чтобы закрепить полученные знания и умения, мы организовали серию концертов и театральных постановок, основанных на произведениях татарских авторов (Габдулла Тукай «Эш беткәч, уйнарга ярый» https://disk.yandex.ru/i/0UzULgYl-I7CAQ «Шүрәле һәм чәк-чәк сере» https://disk.yandex.ru/i/0UzULgYl-I7CAQ )

Классическая литература татарского народа представляет собой богатый источник художественных образов, нравственных уроков и культурных традиций. Через сказки, притчи, пословицы дети знакомятся с особенностями

мировоззрения предков, усваивая моральные ценности и нормы поведения. Фольклорные произведения обладают особой силой воздействия на детскую психику благодаря простоте сюжета, образному языку и ясности идей. Именно поэтому включение произведений устного народного творчества в учебный процесс является необходимым условием успешной социализации и адаптации детей к культурной среде региона проживания.

Театрализация литературных сюжетов помогает ребенку глубже осознать смысл прочитанного текста, развивает способность к эмпатии, формирует позитивное отношение к литературе вообще и татарскому языку в частности.

Использование народной музыки и песен помогает развивать музыкально-слуховые способности, улучшает память, активизирует познавательную деятельность малышей. «Туган авылым» музыкаль композициясе https://disk.yandex.ru/i/waVDw5o9Z4fKQg Музыкальное сопровождение спектаклей усиливает эмоциональное восприятие материала, повышает мотивацию детей к изучению родного языка. Так же мы затронули тему татарских народных традиций. Татарский народ славится своими многовековыми традициями и обычаями, которые уходят корнями в глубь истории («Кич утыру йоласы» https://disk.yandex.ru/i/lsQu724EMeKsAQ ; «Солдат озату йоласы» https://disk.yandex.ru/i/Kmg20X5ldKZBIw ). Эти мероприятия позволили детям продемонстрировать свои успехи перед родителями и сверстниками, а также почувствовать гордость за достигнутые результаты.

Таким образом, сегодня современные педагоги активно используют идеи и разработки классиков татарской педагогики, адаптируя их к современным условиям и требованиям федеральных образовательных программ. Создание интерактивных площадок, мастер-классов, экскурсий и праздников становится важным элементом повседневной практики детских садов.

В своей творческой работе мы смогли добиться высокого уровня обучения татарскому языку с использованием театра и музыки. Полученные результаты подтверждают, что интегративные методы влияют на успешность освоения детьми языка, национальной культуры и демонстрирует перспективность использования наследия татарских просветителей в современной практике дошкольного воспитания.

**«Литература»**


Алимова Г.М., Ягудаева Ф.Н. Интеграция искусств в поликультурной образовательной среде // Вестник Казанского университета культуры и искусств. 2019. № 3. С. 105-110.

Байкова Л.А. Развитие речи детей дошкольного возраста через театрализацию / Науч.-метод. журнал «Детский сад XXI век». 2018. № 2. С. 24-30.

Губанова Н.Ф. Современные технологии обучения иностранным языкам // Образование и наука. 2019. № 4. С. 134-141.

Миннегулова Э.И. Использование народных традиций в формировании этнического самосознания младших школьников // Ученые записки Казанского гос. ун-та. Серия гуманитарных наук. 2018. Т. 160. № 2. С. 164-171.

Салимова Х.Г. Исследование проблем этнокультурного воспитания детей в дошкольных образовательных организациях // Казанский педагогический журнал. 2019. № 3. С. 115-120.

Сулейманов Р.Б. Современная концепция этнопедагогики в республике Татарстан // Вопросы философии. 2018. № 1. С. 118-123.

Чанышева Д.С. Применение театральных приемов в работе с детьми раннего возраста // Мир науки, культуры, образования. 2017. № 6. С. 211-215.


## ДУХОВНО-НРАВСТВЕННОЕ ВОСПИТАНИЕ МОЛОДОГО ПОКОЛЕНИЯ ЧЕРЕЗ СОЗДАНИЕ ФОТОКНИГИ ПАМЯТИ. ИСТОРИЯ СЕМЬИ ХАБИБУЛЛИНЫХ


***Хабибуллина Д.И.***
*г. Казань, ФГАОУ ВО «Казанский Федеральный Университет», Институт управления экономики и финансов, 1 курс*

***Ибрагимов И. Р.***
*методист ИПО КФУ, г.Казань*

Духовно-нравственное воспитание — один из важных аспектов воспитания, направленный на усвоение подрастающими поколениями и претворение в практическое действие и поведение высших духовных ценностей. Основной задачей которого является формирования нравственной культуры личности в достижении оптимального сочетания традиций и новаций, в соединении конкретного опыта личности и всего богатства общественной морали. [3]

Через постепенные изменения нрава, характера, мотивов, приоритетов человека к милосердию, ответственности за свои мысли, слова, поступки посредством применения приобретённых знаний.

Духовно-нравственное воспитание начинается с рождения человека и идёт всю жизнь, через общение, трудовую деятельность, повседневные дела. [1]

Актуальность проблемы духовно-нравственного воспитания связана с тем, что в современном мире человек живёт и развивается, окружённый множеством разнообразных источников сильного воздействия на него как позитивного, так и негативного характера (это, в первую очередь, средства массовой информации и коммуникации, неорганизованные события окружающей среды), которые постоянно оказывают огромное влияние на неокрепший интеллект и чувства молодого человека, на его формирующуюся сферу нравственности.

Современное общество находится в состоянии глубокого кризиса. Был утерян тот духовный стержень, который многие века взгревал жизнь в сердцах людей. Теперь, для выхода из этого кризиса следует заняться прежде всего вопросами воспитания. И именно воспитания, а уже затем образования. Безусловно, семейное воспитание играет ведущую роль в формировании нравственного стержня личности [2].

Семья как устойчивая социальная общность выступает мощным фактором формирования человека, передачи социального опыта, исторической памяти людей, этнокультурных традиций. Необходимо возвратить воспитание в семью, признать родителей главными воспитателями, ответственными за экологию детства, и вести поиск путей педагогического сотрудничества и добровольного общения с родителями. Для установления сотрудничества и укрепления традиционных ценностей у молодёжи предлагается создать фотокнигу памяти о предках семьи на основе данных предшествующих поколений и сбора информации в архивах и интернет-ресурсах. Фотокнига памяти будет также способствовать:

- узнаванию и укреплению национального самосознания, важного для сохранения самобытности общества, сохранения истории и определения будущее нашего народа;

- обеспечению исторической преемственности поколений, сохранения, распространения и развития национальной культуры, воспитания бережного отношения к историческому и культурному наследию народов России;

- воспитанию патриотов России.

- укрепление родственных связей в семьях

Моя семья, семья Хабибуллиных, со своими родственниками создала и активно продвигает среди подрастающего поколения идею создания фотокниг памяти. Фотокнига памяти нашей семьи «О героях былых времён» была создана в 2025 г. нашим родственником Сарваровым А.С. к 80-летию Победы в Великой Отечественной войне. Была проделана большая работа по собранию информации. Многие семейные связи были возобновлены как между старшим поколением, так и молодым. Удалось собрать информацию о 36 родственниках. Книга оказала большое эмоциональная влияние на молодёжь семьи, вызвав у них чувство гордости за своих предков и уважение к истории своей страны. Фотокнига памяти позволила мне узнать о родоначальниках семьи, моих прапрадедов.

Наше старшее поколение - мой прапрадед Хабибуллин Габдулла (Абдулла) Хабибуллович и его родной брат Хабибуллин Набиулла Хабибуллович, были еще участниками Первой мировой войны. Набиулла Хабибуллович также участвовал в Гражданской войне, обороняя город Мензелинск от Колчака. Старшее поколение было боевым и их детям (Фатима, Фаиз, Разия и Рафгат) пришлось воевать в Великой Отечественной войне. Мой прадедушка был самым младшим (ему было 7 лет, когда началась война).

Хабибуллина Фатима Набиулловна (1919г.р) – старший лейтенант, гв Капитан и последнее звание подполковник медицинской службы. В 1942г она ушла на фронт добровольцем. Служила в госпитальном взводе 186 медико-санитарного батальона. Благодаря ее самоотверженному труду в тяжелейших условиях сумела отстоять жизнь и здоровье сотням бойцов и офицеров Красной Армии. Награждена Орденом «Красная звезда», медалью «За боевые заслуги», Медалью «За победу над Германией в Великой отечественной войне 1941-1945гг»

Хабибуллин Фаиз Набиуллович, 1921 г.р. – был старшим лейтенантом, награжден медалью «За боевые заслуги», медалью «За оборону Кавказа», Медалью «За победу над Германией в Великой отечественной войне 1941-1945гг».

Хабибуллин Фарит Хабибуллин Хабибуллович (1920 г.р) – был участником Великой Отечественной войны, получил ранение и был комиссован, вернулся в родную деревню и работал механизатором в колхозе. Награжден Орденом Отечественной войны 2 степени.

Абдуллина (Хабибуллина) Разия Абдулловна (1922г.р) – Фамилия Абдуллина дана по имени Отца Абдулла (Габдулла), в то время так было принято. В июле 1940г она закончила Мензелинское медицинское училище. С началом Великой Отечественной войны 5 августа 1941г была призвана на службу в должности младшей медсестры в эвакуационный госпиталь 3648. После расформирования этого госпиталя была зачислена на должность

медицинской сестры в эвакуационный госпиталь 4642 в Казани, где служила до 1946г до расформирования госпиталя.

Из воспоминаний Разии Абдулловны – в госпиталях сложнее всего было ухаживать за раненными бойцами, лишившимся на войне рук и ног. Им надо было помочь преодолеть физическую боль и душевную травму, помочь смириться с инвалидность и продолжать жить дальше.

Награждена медалью «За победу над Германией в Великой отечественной войне 1941-1945гг», «20 лет победы в ВОВ», «30 лет победы в ВОВ» и «40 лет победы в ВОВ».

Абдуллин (Хабибуллин) Равгат Абдуллович (1924 г.р.), фамилия также дана по имени отца. Рафгат окончил школу с отличием и досрочно в 16лет! Он имел право поступить в то время в любой ВУЗ СССР без экзаменов. При поступлении в технический ВУЗ у него была бы бронь до конца войны. Но он поступил в педагогический институт, откуда по достижении 18 лет призывали на фронт. В 1942г от был призван на фронт. Абдуллин Рифгат Абдуллович был ротным писарем и ему в первых рядах, атакующих не положено было быть, так как при нем была ротная документация, которую он должен был вести в любых условиях. Необходимо было собирать документы погибших и заполнять формы о безвозвратных потерях и раненых, оформлять и отсылать извещения (похоронки) о гибели бойцов и др. Поэтому его место было на расстоянии 500-600 м от первых рядов атакующих. Но рядом с ним взорвалась вражеская мина. Погиб он в июле 1944г в западной Украине.

Книга «О героях былых времён» великое наследие Хабибуллиных, которое будет передаваться из поколения в поколение, воспитывать уважение к истории семьи и страны, напоминать о подвиге предков. Фотокнига памяти служит мощным ресурсом для формирования духовных и нравственных ориентиров у молодого поколения семьи. На примере моей семьи Хабибуллиных, демонстрируется практический механизм передачи ценностей между поколениями.

Литература

1. Результаты опроса опубликованы в книге: Российское общество и вызовы времени. Кн. 2 / Под ред. М. К. Горшкова и В. В. Петухова. М.: Весь Мир, 2015. Проект РНФ № 14–28–00218 «Динамика социальной трансформации современной России в социально-экономическом, политическом, социокультурном и этнорелигиозном контекстах».

2. Даниленко Б. Православная традиция и современные реалии в российской школе XXI века// Журнал Московской Патриархии. — 2008. — № 3. — С. 44–49;

3. Петрова В. И. Азбука нравственного взросления. СПб.: Питер, 2007;

4. Сарваров А.С. Фотокнига память «О героях былых времён» г. Магнитогорск 2025

## ТӘРБИЯ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

***Валиуллина А.Р.***

*Казан шәһәре, «№188 нче балалар бакчасы» МАМБУ, РТ*

Бай һәм күп гасырлы тарихы булган татар халкы яшәү дәвамында төрле сәяси, социаль һәм мәдәни каршылыкларга юлыккан. Бу шартларда милли үзенчәлекне саклауда, рухи-әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруда һәм алга китешкә омтылуда татар мәгърифәтчеләре аерым роль уйный. Аларның XIX – XX гасыр башында җәелдерелгән эшчәнлеге җәмгыять тормышының төрле өлкәләрен – мәгариф, фән, әдәбият, театр, журналистика һәм башкаларны колачлаган. Әлеге мәкалә үсеп килүче буынны тәрбияләүдә һәм милли үзаң формалаштыруда татар мәгърифәтчеләренең ролен тикшерүгә багышлана.

XIX гасыр татар халкы өчен тиз үзгәрә торган дөньяда үз урынын эзләү чоры була. Россия империясенә керү, Европа идеяләренең таралуы, икътисадый үзгәрешләр – болар барысы да татарлар алдында яңа мәсьәләләр куя һәм традицион кыйммәтләрне яңадан аңлауны таләп итә. Бу шартларда нәкъ менә мәгърифәтчеләр үзләренә милләтне яңа чынбарлыкка җайлаштыру, аның мәдәни мирасын саклау һәм прогрессны стимуллаштыру бурычын алганнар.

Аларның эшчәнлеге түбәндәге төп бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1. Белем тарату: дини фәннәр белән беррәттән дөньяви фәннәр, телләр, тарих һәм география укытылган яңа ысуллы мәктәпләр (җәдидчелек) челтәрен булдыру.

2. Милли әдәбият һәм сәнгатьне үстерү: әдәби тел формалаштыру, татар халкы тормышын чагылдырган әдәби әсәрләр иҗат итү, театраль куелышлар оештыру.

3. Тарих һәм мәдәниятне өйрәнүгә ярдәм итү: фольклор җыю, тарихи чыганакларны өйрәнү, фәнни экспедицияләр оештыру.

4. Мәгариф һәм мәдәниятне пропагандалау: татар телендә газета-журналлар чыгару, мәдәни чаралар оештыру.

Татар мәгърифәтчеләренең төп казанышларының берсе: җәдидчелек мәктәпләре булдыру. Бу мәктәпләр, традицион мәдрәсәләрдән аермалы буларак, заманчарак һәм күпкырлы белем бирүне тәкъдим иткәннәр. Аларда дини фәннәр генә түгел, математика, география, тарих, табигать белеме, шулай ук рус теле һәм башка чит телләр кебек дөньяви фәннәр дә укытылган.

Мәгариф өлкәсендә агарту эшчәнлегенең иң ачык мисаллары булып:

1. Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889): татар мәгарифендә җәдидчелеккә нигез сала. Ул иске укыту методларын тәнкыйтьли һәм табигый фәннәрне, Европа мәдәниятен өйрәнергә чакыра. Мәрҗани рухи яктан үскән, мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле шәхес тәрбияләү кирәклеген таләп итә. Мисал өчен, “Мостафад әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” дигән хезмәтендә Мәрҗани татар халкының бай мәдәни мирасын һәм аны саклап калу кирәклеген күрсәтеп, аның тарихына игътибарны юнәлтә.

2. Каюм Насыйри (1825-1902): танылган педагог, этнограф һәм язучы. Аның тарафыннан укучыларда логик фикерләүне һәм иҗади сәләтләрне үстерүгә юнәлдерелгән яңа дәреслекләр һәм укыту методикалары эшләнгән. Насыйри шулай ук татар фольклорын җыю һәм өйрәнү белән шөгыльләнә, аны үзенең педагогик эшчәнлегендә куллана. К. Насыйри “Татар теле әлифбасы”н иҗат итә, анда халык иҗаты үрнәкләрен, мәкальләр һәм

әйтемнәрне балаларга белем бирүне кызыклырак һәм аңлаешлырак итү өчен куллана [Гайнуллин, электрон ресурс].

3. Галимҗан Ибраһимов (1887-1938): күренекле җәмәгать эшлеклесе, педагог, әдәбият белгече һәм публицист. Ул мәгариф системасын реформалаштыру, укыту программаларына татар халкының тарихын һәм мәдәниятен кертү, милли әдәбиятны үстерү яклы. Г. Ибраһимов яшьләрдә патриотизм һәм милли дәрәҗә хисе тәрбияләүнең мөһимлеген ассызыклый. Язучы үзенең педагогик хезмәтләрендә татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм теле өйрәнелә торган милли мәктәп идеясен актив алга сөрә. Ул мондый мәктәп яшь буында милли үзаң формалаштырырга һәм аны үз халкына хезмәт итүгә әзерләргә мөмкинлек бирәчәк дип саный.

"Безнең көннәр" — аның шул чорның кискен социаль мәсьәләләренә кагылган һәм милли үзенчәлек темасын күтәргән әһәмиятле әсәрләренең берсе.

4. Фатих Кәрими (1870-1937): язучы һәм педагог, җәдид мәктәпләренә нигез салучы. Ул белемнәрне күрсәтмәлелеккә һәм практик куллануга нигезләнгән яңа укыту методларын актив рәвештә кертеп җибәрә. Хатын-кызлар мәгарифе тарафдары булып тарихка кереп кала. Кәрими мәгърифәтчелек һәм милли үзаңны пропагандалау өчен мөһим рупорга әверелгән "Вакыт" газетасына нигез сала һәм аны чыгара.

Яңа ысуллы укыту мәктәпләре укучыларга белем генә биреп калмыйча, аларда милли горурлык хисе, үз мәдәниятенә һәм тарихына хөрмәт, белемгә һәм алгарышка омтылыш тәрбияли. Алар милләтнең киләчәгендә мөһим роль уйнарга тиешле яңа буын татар интеллигенциясен әзерлиләр.

Татар мәгърифәтчеләре милли әдәбият һәм сәнгать үсешенә зур әһәмият бирәләр. Алар әдәбият һәм сәнгатьнең милли үзаң тәрбияләү һәм формалаштыруның көчле чаралары булуын аңлыйлар.

Әдәби тел формалаштыру өстендә мәгърифәтчеләр зур хезмәт куялар. Диалектларга карамасатан, барлык татарларга аңлаешлы булган бердәм әдәби тел булдырырга омтылалар.

Бүгенге көндә балалар бакчасында милли үзаң формалаштыруга һәм туган телгә, мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә хөрмәт тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирелә. XIX-XX гасырлардагы татар мәгърифәтчеләренең идеяләре аеруча актуаль. Тәрбиячеләр көндәлек эшләрендә аларның мирасын кулланалар, бу исә белем бирү процессын баетырга һәм балалар үсеше өчен уңайлы мохит тудырырга ярдәм итә.

Тәрбия өлкәсендә әдәби әсәрләр зур урын алып торалар. Язучылар һәм шагыйрьләр татар халкының тормышын, аның тарихын, гореф-гадәтләрен, шулай ук аның хыялларын һәм омтылышларын чагылдырган әсәрләр иҗат иткәннәр.

Театр — яктылыкка, нурга илтә,

Кире юлга җибәрми, уңга илтә. – дип яза “Театр” шигырендә Г. Тукай. Беренче татар пьесасы язылган көннән башлап, бүгенге көнгә кадәр театр татар халкының мәдәни тормышының мөһим үзәгенә әверелә. Сәхнәдә актуаль социаль һәм сәяси мәсьәләләрне күтәргән, шулай ук татар халкы тарихының героик битләре турында сөйләгән пьесалар куелып килә.

Татар әдәбияты һәм сәнгате үсешенә зур өлеш керткән төп шәхесләрне без белергә тиешле. Алар арасында Г. Тукай, М. Җәлил, К. Тинчурин исемнәре бар.

Габдулла Тукай (1886-1913) – бөек татар шагыйре, хәзерге татар әдәбиятына нигез салучы. Аның шигырь һәм поэмалары туган халкына мәхәббәт, аның киләчәгенә ышаныч, гаделлеккә һәм иреккә омтылыш белән сугарылган [Низамов, электрон ресурс].

Шагыйрьнең “Туган тел” шигыре татар халкының гимны, аның бердәмлеге һәм мәдәни үзенчәлеге символына әверелде.

Муса Җәлил (1906-1944) – фашистлар концлагерендә һәлак булган каһарман шагыйрь. Аның төрмә диварларында язылган шигырьләре татар халкының фашизмга каршы көрәштә батырлык һәм ныклык символына әверелде. “Моабит дәфтәрләре” шигырьләр циклы дошманны җиңүгә ышаныч

һәм Ватанга мәхәббәт белән сугарылган патриотик поэзиянең ачык мисалы булып тора.

Кәрим Тинчурин (1887-1947) – күренекле драматург, режиссер һәм актер. Ул тамашачылар арасында зур популярлык казанган бик күп пьесалар иҗат итә. Тинчурин татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә.

“Зәңгәр шәл” пьесасы К. Тинчуринның иң танылган пьесаларыннан берсе. Ул мәхәббәт, хыянәт һәм гаделлек өчен көрәш турында [Низамов, 2002: 111].

Татар мәгърифәтчеләре иҗат иткән әдәбият һәм сәнгать милли үзаңны формалаштыруда, милли горурлык хисен ныгытуда һәм алга китешкә омтылуны стимуллаштыруда мөһим роль уйныйлар. Шул исәптән татар язучыларының әсәрләре балалар бакчасында да кулланыла. Бакчада уздырылган бәйрәмнәр Г. Тукай, М. Җәлил шигырьләреннән башка узмыйлар. Балалар язучыларның иҗаты аша үзләрендә туган илгә, әти-әнисенә, тарихка һәм гореф-гадәтләргә карата ихтирам, ярату хисе тәрбиялиләр.

Мәгърифәтчелек эшчәнлегендә вакытлы матбугат мөһим роль уйный. Татар телендәге газета-журналлар актуаль социаль һәм сәяси мәсьәләләр буенча фикер алышу, белем һәм идеяләр тарату, җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру өчен платформага әверелә.

Исмаил Гаспринский (1851-1914) Россияда беренчеләрдән булып төрки телдә “Тәрҗеман” газетасын чыгара башлый. Ул беренче гомумроссия мөселман басмасы булудан тыш, җәдидчелек идеяләрен таратуда һәм төрки халыкларның бердәмлеген пропагандалауда мөһим роль уйный. Газета тарих, мәдәният, мәгариф буенча мәкаләләр, шулай ук мөселман җәмгыятьләре тормышыннан яңалыклар бастыра.

“Шура” журналына Ризаэтдин Фәхретдинов (1859-1936) нигез салган. Әлеге журнал дин, әхлак, мәгариф һәм мәдәният мәсьәләләренә багышланган. Журнал әйдәп баручы галимнәр һәм фикер ияләренең мәкаләләрен, шулай ук әдәби әсәрләрен бастырып чыгара.

“Вакыт” газетасының баш мөхәррире Фатих Кәрими татар мәгърифәтенә чиксез зур өлеш кертә. Җәдит хәрәкәтенә ярдәм итүдә, прогрессив материаллар, шул исәптән хатын-кызлар белеме һәм хокуклары турындагы мәкаләләр бастыруда әһәмиятле роль уйный.

Татар вакытлы матбугаты мәгърифәтчеләр кулында аларга җәмәгатьчелек фикеренә йогынты ясарга, белем һәм идеяләр таратырга, милли үзаң формалаштырырга мөмкинлек бирүче мөһим коралга әверелә.

Беренче татар газетасы басылып чыккан көннән алып, бүгенге көнгә кадәр газета-журналлар үз кыйммәтен югалтмыйлар. Мәсәлән, балалар бакчасында өлкән төркемнәр белән газета-журналлар карау аерым бер урын алып торалар. Шулай ук балалар тәрбиячеләр ярдәме белән үзләре газета ясыйлар.

Балалар бакчасында татар мәгърифәтчеләренең идеяләрен куллану балаларда милли үзаң, туган телгә, мәдәнияткә һәм гореф-гадәтләргә хөрмәт формалаштыруга ярдәм итә. Бу аларга шулай ук белемле, рухи яктан бай һәм үз илен патриотик рухта яратучы гражданнар булырга ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Гайнуллин М., Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте [электрон ресурс] URL https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1952-8/tatarlarda-mgbriftchelek-khrkte (мөрәҗәгать итү вакыты: 20.10.2025).
2. Низамов Р. А. Татар халык педагогикасы: уку ярдәмлеге/ Р. А. Низамов, Җ. Г. Нигъмәтҗанов. — Казан: Мәгариф, 2002. – 111 б.
3. Низамов Р. Халкыбыз мәгърифәтчеләре/ Р. А. Низамов, Җ. Г. Нигъмәтҗанов. [электрон ресурс] URL http://gabdullatukay.ru/tukay-science/scientists/nizamov-r-nigmetjanov-j-halkybyz-megrifetchelere/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 20.10.2025).
4. Садыйков М., Татар мәгърифәтчеләре турында яңа хезмәт/ М. Садыйков, Х. Мәхмүтова [электрон ресурс] URL: https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1977-3/tatar-mgbriftchelege-turynda-yaa-khezmt (мөрәҗәгать итү вакыты: 20.10.2025).

# ПРОБЛЕМА ИЗУЧЕНИЯ РОЛИ ТАТАРИЗМОВ В ОБОГАЩЕНИИ ЛЕКСИКИ РУССКОГО ЯЗЫКА

***Мухаметзянова Л.Х.***
*учитель русского языка и литературы МБОУ «СОШ с.Ядыгерь» Кукморского муниципального района Республики Татарстан*

Два народа, русский и татарский, живут рядом уже несколько веков. Одной из сфер взаимного влияния наших народов является язык. В настоящее время в Республике Татарстан татарский язык стал одним из государственных языков республики, широко изучается на всех уровнях образования. Русский язык остается в Республике Татарстан языком межнационального общения и широко используется во всех областях общественной жизни, науки и культуры.

Как показывает исторический опыт, у каждого языка, у каждой культуры есть только им присущая миссия и они вносят свой вклад в развитие мировой культуры. Соответственно, система обучения татарскому языку в русской школе должна видеть эту миссию и создавать необходимые условия для формирования у школьников таких качеств, как компетентность в межкультурном диалоге, коммуникативность, открытость. От успешного решения этой актуальной лингвометодической задачи зависит, станет ли татарский язык средством реального и полноценного межкультурного общения.

Однако в середине июля 2017 года президент России Владимир Путин во время выступления в Йошкар-Оле заявил о недопустимости изучения неродных языков в ущерб русскому языку. Кому-то эти слова оказались на руку, и в Татарстане сразу начало набирать силу движения против обязательного изучения татарского. Разгорелся так называемый языковой скандал. Особо неприятен при этом тот факт, что против изучения татарского языка настроились даже те, для кого язык является родным. Одной из причин такого их поведения я считаю то, что люди просто не имеют представления о

том, что благодаря татарским заимствованиям лексика русского языка стала богаче, точнее и выразительнее.

«Все народы меняются словами и занимают их друг у друга», - писал В.Г.Белинский. Татарские заимствования составляют один из слоев заимствованной лексики в русском языке. Русский язык активно пользуется татарскими заимствованиями, начиная ещё с домонгольского времени. В разные исторические периоды в русский язык вошло значительное количество тюркских слов . Они усваивались по-разному – книжным или устным путем, через разговорную речь. В результате живого общения русского и тюркских народов они нередко подвергались воздействию со стороны русской фонетики, в соответствии с нормами русского произношения переоформлялись или получали иное этимологическое толкование.

Татарские заимствования настолько прижились в русском языке, что порой сложно поверить, что то или иное слово имеет татарские корни. Без многих татаризмов русский язык не может обойтись и вовсе.

Так, мной были проведены эксперименты с участием разновозрастных обучающихся. Я предложила посмотреть на следующий ряд слов: амбар, атаман, арбуз, бояре, богатырь, бурундук, барсук , внук , гуляш, деньги, ералаш, есаул, книга, князь, кремль, колбаса, кирпич, карандаш, корабль, кувшин, маяк, стол, сундук, скатерть, шаль, пельмень, изба, ямщик. Из этих слов нужно было выделить те, которые, по мнению учеников, являются татарскими заимствованиями. Среди 20 участников эксперимента 8 человек татарскими посчитали 3-4 слова, 7 человек – 5-6 слов, 5 человек - до 10 слов. В действительности же татарскими заимствованиями являются все из них. Так, можно сделать следующий вывод: многие даже не догадываются о том, что в нашей повседневной русской речи много татарских заимствований. Почти всех участников поразил тот факт, что все слова имеют татарские корни.

Далее я предложила прочитать следующий текст. «Ближе к вечеру мы подъехали к <u>Кремлю</u>. <u>Колёса</u> уже устало скрипели, и люди на арбе почти спали. С <u>минарет</u>а послышались звуки азана. Путники забыли про свой багаж,

и бочки с кувшинами, казалось, тоже прислушались. Сундуки со скатертями и сарафанами уныло дожидались времени, когда попадут на базар». Задание было следующим: заменить подчёркнутые слова татарского происхождения на слова нетатарского происхождения. Задание вызвало трудности. Колёса арбы назвали шинами, бочки – бидонами, кувшины – графинами, сундук – коробкой или ящиком. В целом получился примерно такой текст: «Ближе к вечеру мы подъехали к КРЕПОСТИ. ШИНЫ уже устало скрипели, и люди на арбе почти спали. С БАШНИ послышались звуки азана. Путники забыли про свой багаж, и БИДОНЫ с ГРАФИНАМИ , казалось, тоже прислушались. ЯЩИКИ с КЛЕЁНКАМИ и ПЛАТЬЯМИ С КОРОТКИМИ РУКАВАМИ уныло дожидались времени, когда попадут на РЫНОК». Здесь налицо тот факт, что с заменой татарских слов текст потерял точность и выразительность, стал комичным и лишённым смысла.

Литература


1. *Добродомов И.Г. Некоторые вопросы изучения тюркизмов в русском языке // Вопросы лексики и грамматики русского языка. - М., 1967. - С. 364-374.*
2. *Румянцева Е.В. Русский язык: справочник для школьника 5-11 классы : Справочник серии "Талапкер".- Астана: Арман-ПВ, 2009.- 316 с.*
3. *Фасмер М. «Этимологический словарь русского языка». 1-е издание: 1964–1973; 2-е издание: 1986–1987 (редактор русского текста М. А. Оборина); 3-е издание: 1996; 4-е издание: 2006. – Режим доступа: https://vasmer.lexicography.online*
4. *Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке, издательство "Наука", Алма-Ата 1976 г. – Режим доступа: http://liveangarsk.ru/files/commentuploads/409581/985-p1abf2i5rh126a5229s612v9e564.pdf*


## 3D-МОДЕЛИРОВАНИЕ В ИСКУССТВЕННОМ ИНТЕЛЛЕКТЕ И ЕГО ПРИМЕНЕНИЕ ВО ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ПО МАТЕМАТИКЕ


***Хафизова Р. Д.***

*магистр 2 курса кафедры методологии обучения и воспитания, Институт Психологии и Образования, Казанский(Приволжский)*

*федеральный университет г. Казань Учитель математики МБОУ «Большеатнинская СОШ» Атнинского муниципального района РТ*

***Миннибаев Эмиль Шарифович***

*доцент, кандидат биологических наук Институт психологии и образования, Казанского Федерального Университета*

**Аннотация:** в статье рассматривается роль 3D-моделирования в искусственном интеллекте и его применение во внеурочной деятельности по математике. Анализируются современные инструменты для создания 3D-моделей с использованием ИИ, а также предлагаются практические примеры их интеграции в образовательный процесс. Особое внимание уделяется пространному мышлению, на его развитие, мотивации учащихся к изучению математики. Применение 3D технологий позволяют в образовательном процессе развивать мышление, современные компетенции учащихся, а также придают интерес к техническим профессиям.

**Ключевые слова**: искусственный интеллект, моделирование, 3D-моделирование, математика, внеурочная деятельность, обучение, применение, межпредметные связи.

Современные технологии стремительно развиваются и искусственный интеллект становится неотъемлемой частью образовательного процесса. 3D-моделирование, объедененное с возможностями ИИ, открывает новые перспективы для изучения математики, позволяет визуализировать абстрактные концепции. Во внеурочной деятельности такие инструменты помогают вовлечь учащегося в исследовательский проект, развить креативное мышление и навыки работы с цифровыми технологиями. Раз есть современные технология, то современный учитель должен уметь ими правильно обращаться и показывать остальным как его использовать. Но вот вопрос, готова ли образовательная система к этим изменениям?..

Как мы знаем, 3D-моделирование – это процесс создания трехмерных объектов с помощью специализированного программного обеспечения. С развитием ИИ появились инструменты, упрощающие этот процесс: нейросети

могут генерировать модели на основе текстовых описаний, достраивать сложные геометрические фигуры и даже анимировать объекты. Использование 3D-моделирований дает преимущества в наглядности, практическом применении, развитии Soft Skills обучающегося. Сложные математические объекты становятся видимыми и интерактивными, учащиеся сами могут создавать модели для решения задач по стереометрии, и формируют у себя аналитическое и пространственное мышление.

Например, генерация многогранников с помощью AI. Ученики используют нейросетевое ПО (сюда подойдет Kaedim или Deep Dream Generator), чтобы создать 3D-модели икосододекаэдра или усеченного куба. Они анализируют полученные модели, вычисляют количество граней, ребер, вершин, проверяя формулу Эйлера. Результаты в конце визуализируются в Blender или Tincerkard и сравниваются с классическими построениями. Результатом является повышение интереса к геометрии и лучшее понимание трехмерных фигур.

В математике есть такие темы, для изучения которых требуется наглядность того или иного изучаемого понятия. Так при переходе обучения от двухмерных объектов к трехмерным, мы начинаем изучать объемные фигуры, их элементы, объемы и площади.

Константин Дмитриевич Ушинский заметил: «Детская природа требует наглядности». Если при изображении плоских фигур все его свойства видны на чертеже, то при построении геометрических объектов в пространстве эта очевидная наглядность теряется. Поэтому для наиболее эффективного результата при изучении данной темы необходимо на уроке демонстрировать модели фигур, чтобы дети увидели, что они имеют определенную площадь поверхности, объем и занимают определенное место в пространстве. Эти модели могут быть сделаны из картона, дерева или других материалов.

Таким образом, 3D-моделирование с использование искусственного интеллекта предоставляет уникальные возможности для внеурочной деятельности по математике. Оно делает сложные концепции более

доступными и стимулирует исследовательскую деятельность и готовит учащихся к работе с современными технологиями. Такие внедрения в образовательный процесс требуют минимальные технические ресурсы, но дает колоссальный значимый эффект.

**Литература**

1. 3D-моделирование. Внеурочная деятельность: учебное пособие. Косопов Д.Г., 2021 г.-112 стр.

2. Каменев Р. В., Лейбов А. М., Осокина О. М. Применение 3D-принтеров в образовании // Решетневские чтения. - 2025. - Т. 3. - С. 83-87.

3. Шегай И. Н. «3D-моделирование и 3D-печать во внеурочной деятельности в контексте реализации ФГОС нового поколения» // «Информатика в школе», 2020, №1, с. 16–25.

## ЦИФРОВАЯ ТРАНСФОРМАЦИЯ ПРОЕКТНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ И ЕЁ ВЛИЯНИЕ НА ВОСПИТАТЕЛЬНЫЙ ПОТЕНЦИАЛ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ОРГАНИЗАЦИИ

***Кузнецов Я.А.***

*магистрант 1 курса Казанского федерального университета г. Казань*

**Аннотация**. В статье рассматриваются особенности цифровой трансформации проектной деятельности в образовательных организациях и её влияние на развитие воспитательного потенциала образовательного процесса. Цифровизация проектной деятельности понимается как процесс внедрения цифровых технологий в педагогическую практику, который способствует изменению содержания, форм и методов обучения, а также воспитательной среды. На основе анализа отечественных исследований в области цифрового образования выявлены педагогические и организационные условия, при которых цифровая проектная деятельность становится инструментом формирования личностных и социальных компетенций обучающихся. Сделан

вывод о том, что эффективная интеграция цифровых технологий в проектную деятельность требует системного подхода, ориентированного на развитие воспитательной миссии образования.

**Ключевые слова**: цифровая трансформация, проектная деятельность, воспитательный потенциал, образовательная организация, цифровая среда, компетенции.

Актуальность исследования обусловлена тем, что современное образование переживает глубокие изменения, связанные с процессами цифровой трансформации. Активное внедрение информационных технологий в учебный процесс, развитие сетевых платформ и цифровых инструментов изменяют не только организацию обучения, но и воспитательные механизмы образовательной среды. В условиях цифрового общества образовательные организации выступают не просто как институты передачи знаний, но как пространство формирования личности, социальной ответственности и гражданской активности.

Особое значение в этом контексте приобретает проектная деятельность, позволяющая соединить учебную, исследовательскую и практико-ориентированную работу обучающихся. Внедрение цифровых инструментов усиливает возможности проектного подхода, расширяет горизонты сотрудничества и способствует формированию компетенций XXI века. Однако цифровая трансформация проектной деятельности порождает и новые вызовы: от технологической зависимости до необходимости переосмысления педагогических целей и методов воспитания.

Целью исследования заключается выявление механизмов влияния цифровой трансформации проектной деятельности на воспитательный потенциал образовательной организации и определении условий её эффективной реализации в российской системе образования.

Цифровая трансформация образования представляет собой системный процесс, затрагивающий все уровни образовательной деятельности — от стратегического управления до методики преподавания. Как отмечает А. Ю.

Уваров, цифровая трансформация не сводится к автоматизации учебных процессов, а требует переосмысления педагогических целей, содержания и структуры образовательных программ [4]. Это особенно актуально для проектной деятельности, где обучение строится на принципах самостоятельности, сотрудничества и творческого поиска.

По мнению М. Г. Успаевой и А. М. Гачаева, цифровизация в высшем образовании способствует созданию новой образовательной экосистемы, в которой проектная деятельность становится связующим звеном между обучением, исследованием и профессиональной практикой [5]. Использование цифровых платформ, сервисов совместной работы и инструментов визуализации данных позволяет учащимся развивать критическое мышление, ответственность за общий результат и навыки коммуникации. Всё это усиливает воспитательный потенциал образовательного процесса.

Исследование Дворецкой И., Уварова А. и Тарасовой К. показало, что готовность школ к цифровой трансформации напрямую связана с организационной культурой, степенью открытости педагогов к инновациям и уровнем методической поддержки [2]. Воспитательный эффект цифровой проектной деятельности возможен лишь при создании доверительной среды взаимодействия между учащимися и педагогами, где цифровые инструменты становятся не заменой живого общения, а его расширением.

Цифровая проектная деятельность способствует развитию у обучающихся не только познавательных, но и ценностно-смысловых компетенций.

Как отмечает Е. К. Дмитриева, цифровые образовательные технологии позволяют интегрировать воспитательные задачи в учебный процесс, стимулируя осознание социальной значимости проектной работы [3]. При этом важно, чтобы цифровизация не подменяла воспитание технологизацией, а использовалась как средство личностного и гражданского становления.

Д. З. Ахметова и коллеги указывают, что цифровая образовательная среда создаёт новые возможности для инклюзивности, коммуникации и

индивидуализации обучения, но требует формирования у обучающихся культуры ответственного поведения в сети и этических норм взаимодействия [1]. Таким образом, воспитательный потенциал проектной деятельности в цифровом формате определяется не только техническими возможностями, но и педагогическим дизайном, направленным на развитие гуманистических ценностей.

Обобщая приведённые исследования, можно выделить несколько ключевых механизмов влияния цифровой трансформации проектной деятельности на воспитательный потенциал образовательной организации:

– формирование ответственности и инициативности обучающихся через самостоятельную организацию цифрового проекта;

– развитие коллективных форм работы и коммуникативных компетенций посредством цифровых средств взаимодействия;

– формирование гражданской и цифровой грамотности;

– усиление рефлексивного компонента за счёт цифровых портфолио и систем самооценки.

Эффективная реализация этих механизмов требует системного подхода, включающего разработку стратегии цифровой трансформации, методическую поддержку педагогов, а также мониторинг не только учебных, но и воспитательных результатов.

Подводя итог, можно сказать, что цифровая трансформация проектной деятельности является мощным фактором обновления воспитательной системы образовательной организации. Цифровые инструменты расширяют возможности взаимодействия, способствуют развитию ответственности, социальной активности и гражданской позиции обучающихся. Вместе с тем, успех цифровизации зависит от готовности педагогов, организационной культуры и ориентации образовательного процесса на личностное развитие. Перспективы дальнейших исследований связаны с эмпирическим изучением влияния цифровых проектов на воспитательные результаты и разработкой методических моделей их внедрения.

## Список литературы

Ахметова Д. З., Артюхина Т. С., Бикбаева М. Р. Цифровизация и инклюзивное образование: точки соприкосновения // Высшее образование в России. — 2020. — Т. 29, № 2. — С. 141–150.

Дворецкая И., Уваров А., Тарасова К. Готовы ли школы к цифровой трансформации: результаты мониторинга общеобразовательных организаций // Вопросы образования. — 2024. — № 3. — С. 141–162.

Дмитриева Е. К. Цифровизация образования в России: педагогические эффекты и риски // Педагогика. — 2022. — № 7. — С. 15–24.

Уваров А. Ю. Цифровая трансформация образования в России сегодня // Образовательные технологии. — 2021. — № 4. — С. 23–36.

Успаева М. Г., Гачаев А. М. Цифровая трансформация высшего образования в России // Управление образованием: теория и практика. — 2022. — № 2. — С. 51–59.

## ЧЕЛОВЕК, РОДИНА И ПРИРОДА- ВЕЧНЫЕ ЦЕННОСТИ В ВОСПИТАНИИ ДУХОВНО-НРАВСТВЕННОГО РАЗВИТИЯ ДОШКОЛЬНИКОВ В СОВРЕМЕННОМ МИРЕ

***Шайхиева Г.Н.***
*магистрант 1 курса Казанского федерального университета, г. Казань*
***Ахунзянова А.В.***
*заведующая МАДОУ «Детский сад № 38», г. Казань*
***Иванова О.М.***
*ввоспитатель МАДОУ «Детский сад № 38», г. Казань*
***Харькова О.Л.***
*старший воспитатель г. Казань, МАДОУ «Детский сад № 388», г. Казань*

Человек и природа, люди и окружающий мир, общечеловеческие ценности и чувство патриотизма — это вечные темы, которые объединяют нас. В условиях современного мира, где технологии и потребление стали главными приоритетами, важно помнить о том, что истинные ценности — это не

материальные блага, а духовные ориентиры, которые помогают нам оставаться людьми. Однако, как ни парадоксально, именно в это время, когда мы достигли таких высот, как никогда остро встает вопрос о сохранении природы и духовных ценностей. Угроза экологического кризиса нависла над человечеством, а проблемы экологической культуры, духовности и нравственности стали жизненной необходимостью.

Воспитание любви к природе, уважение к истории и культуре своей страны - это те основы, которые должны быть заложены в каждом ребенке.

Проблема патриотического воспитания подрастающего поколения в настоящее время выходит на первостепенное место современного общества. Традиционные основы воспитания и образования подменяются «заморскими», из вне. Мир ребенка, заполнен другими важностями в их понимании о войне, чувстве гордости, уважение, мало кто считает это жизненной необходимостью воспринимать как часть жизни, истории, будущего.

Каждый человек играет важную роль в сохранении природных богатств и культурных традиций своей страны. Говорить о любви к своему краю и природе недостаточно — необходимо приложить усилия для защиты и сохранения нашего общего достояния. Важно охранять памятники истории и культуры, изучать свое прошлое, чтобы лучше понимать будущее. Единство мыслей, желаний и действий делает нас сильнее и позволяет утверждать, что мы настоящие граждане своей великой страны.

Современная система образования нацелена на решение вопросов патриотического воспитания, педагоги стараются использовать все возможности для знакомства детей с историей и культурой России. Педагоги находят способы привнести элементы патриотизма в повседневную жизнь учеников, будь то прогулки, праздники или беседы.

Будущее государства находится в наших руках, и именно от нас зависит, каким оно станет. Гордость за страну должна проявляться не только словами, но и действиями, направленными на защиту ее целостности и улучшение экологической обстановки. Наша земля, леса, озера и поля — это наследие,

которое принадлежит каждому из нас и должно бережно передаваться следующим поколениям.

Природа всегда была источником вдохновения и жизненной силы для человека. В русской культуре это особенно заметно: леса, реки, поля — все это неотъемлемая часть нашей истории и культуры. Однако в современном мире, где технологии и потребление стали главными приоритетами, мы часто забываем о том, что природа — это не просто ресурс, а живая система, с которой мы тесно связаны.

Утрачиваются духовные ценности и ориентиры. Изменилась не только наша жизнь, но и мы сами. Наверное, это плохо, бесчеловечно не знать простые истины, приоритеты человеческой жизни, цена которого война. Ценя каждую минуту, прожитую сейчас в мирное время, мы осмысливаем каждый шаг своего действия, вкладывая в души подрастающего поколения, ценности гуманизма, отношения к своим поступкам.

Экологическая культура человека напрямую зависит от самого человека, должен обладать экологическим сознанием, уметь отвечать за свои поступки. Современная экологическая этика ищет решения проблем человечества в душе человека. Уважение к жизни, людям, природе, отечеству – это ценности нашей жизни. Мы все - дети природы.

Цель педагогов в работе с детьми строится на бережном введении детей в мир природы, патриотизма, в помощи дать им необходимые знания о Родине, вырастить доброго и ответственного гражданина целой страны, научить ребенка любить свою Родину, беречь ее и заботиться о ней, сформировать нравственные качества у детей.

Мы педагоги воспитываем любовь к Родине, Отчизне с раннего возраста, к родным, родному дому, родному городу, селу, природе – это основа подрастающего поколения. Ведь то, что вложено нами взрослыми, созревает с возрастом ребенка. Это и осознание себя в семье, неотъемлемой частью родного дома, малой Родины. Не имея знаний, опыта, трудно сформировать такие качества как долг, уважение, патриот, нравственность. Чем больше мы

уделим вниманию этим понятиям, тем больше мы воспитаем гражданина Страны.

Семья и домашняя обстановка играют ключевую роль в воспитании. Дома, где есть животные, растения и забота о них, дети первым делом учатся состраданию и ответственности. Беседы о домашних любимцах, возможность делится радостью общения с ними, способствует формированию первой экологической культуры в душе ребенка.

Также значимыми являются детские игры, сказки, загадки, где природа и ее обитатели занимают центральное место. С их помощью дети не только познают, но и развивают эстетические, культурные навыки, красоту окружающего мира и как беречь все это.

Знакомство с малой Родиной также выступает важным моментом в формировании патриотизма. Ребенок, узнавая о своих улицах, традициях, учится замечать красоту или бедственное состояние природы. Это наталкивает их на желание помочь, понять, что же произошло с природой и как помочь? Что способствует чувству ответственности на сохранение своей Родины? И тут приходит чувство сопереживать, побуждающее оказать помощь.

Какая притягательная сила заключена в то, что нас окружает с детства? Почему даже уехав из родных мест, человек вспоминает их с чувством теплоты, гордости, уважения, любви и признания. Свою любовь к родным местам, знания того, чем живет народ, чем занимается, какова его природа и труд. Это важный аспект для человека. Ведь не зря говорят: «Где родился, там и пригодился».

Малая Родина, отечество, Родной край играют значительную роль в жизни каждого человека, роль в жизни маленького человека, но мало говорить о любви к родному краю, природе, ведь еще надо сберечь и сохранить, то, что имеем. Охраняя значимые объекты наследия. Зная прошлое, мы познаем будущее. Мы едины – когда мы непобедимы в своих мыслях, желаниях, чувствах и словах, поступков. Чем больше мы сможем сделать, тем больше

гордости и любви к своей стране Родине, и мы сможем быть полезны ей, и сможем преумножить ее богатство. Будущее страны в наших руках.

Мы должны гордиться, своей страной и не разрушать ее целостность, экологию, от этого зависит все наше богатство и мир на земле.

Любите родную природу, озера, леса и поля. Это то, что с нами навсегда, навеки. Земля наша, на которой мы живем и родились. Так будем же, люди, все вместе. Мы к ней относится добрей. Поэтому важно быть и чувствовать принадлежность к своей Родине, и будущему, где ядром является ее духовность, богатство жизненного опыта, культура самого человека, его чувства, поступки, его взгляды, убеждения, стойкость в своих намерениях.

Прошло уже 80 лет с окончания Великой Отечественной войны, но память о ней должна жить вечно. Выражение «Никто не забыт, ничто не забыто» не должно оставаться пустым лозунгом, а стать моральным законом для каждого россиянина. Победа ковалась не только на фронте. Женщины, старики, дети работали на заводах, в полях, рыли окопы, спасали раненых. Все для Победы, все для солдат. Праздник Победы над фашизмом навсегда останется в исторической памяти народов России и других стран, по территории которых прокатился смертоносный фашизм. Сколько, бы, не прошло лет, новые поколения людей будут с благодарностью вспоминать воинов ВОВ, принесших долгожданную победу, склоняя головы перед памятью тех, кто не вернулся с поля боя.

Новые поколения должны помнить подвиг ветеранов и чтить их память, чтобы трагедия войны никогда не повторилась. Бессмертие героев и благодарность потомков — залог мирного будущего нашей страны.

**Литература**

1. Антонов Ю.Е., Левина Л.В. Как научить детей любить Родину/ Москва.: АРКТИ, 2003, - 166с.

2.Дерябо С.Д., Ясвин В.А. Экологическая педагогика и психология/ Ростов-на-Дону: Феникс, 1996, - 480с.

3.Тайчинов М. М. Духовно-нравственное воспитание в процессе общения с природой// Среднее профессиональное образование. – 2011. –№ 5. - 23-24с.

# УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА ТУГАН ЯК ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ

***Шиһапова Г. Х.***
*Татарстан Республикасы Арча районы МБГБУ “Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе” укытучысы*
***Салахова И. Г.***
*Татарстан Республикасы Арча районы МБГБУ “Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе” укытучысы*

Бүгенге көндә төп бурычларыбызның берсе – һәрьяктан камил булган туган илен яратучы зыялы шәхес тәрбияләү. Ә ул, үз чиратында, туган телебезне яратуны, үз халкыңның мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Бу бурычны тормышка ашыруның күптөрле юнәлешләре була. Балаларга белем һәм тәрбия бирүдә туган якны өйрәнү алыштыргысыз зур урын алып тора. Билгеле булганча, туган илгә мәхәббәт, хакыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, гомумән, укучыларда милли үзаң, уңай караш тәрбияләү – һәр укытучы алдында торган төп бурыч. Электән кешене тарихка җәлеп итүнең иң актив һәм иҗади формаларыннан берсе булып туган якны өйрәнү торган.

Туган төбәк, туган шәһәр, туган җир.... Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчен дә газиз һәм кадерле булырга тиеш. Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный. Танылган галим Әнвәр Хуҗиәхмәтов фикеренчә, патриотик хисне басым ясап, указлар нигезендә генә булдырып булмый. Бу эшчәнлек бала тугач ук башланырга тиеш.

Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә.Укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш.

Туган як тарихын өйрәнү бүгенге көндә бик**актуаль**,чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш.

Туган як тарихын өйрәтүнең төп максаты: туган җиребезнең тарихын һәм гореф- гадәтләрен өйрәнеп, әхлаклы, милли аңлы шәхес тәрбияләүгә ирешү. Бу эшне башкарганда түбәндәге бурычлар куела:

-Укучыларның танып белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;

-Үз халкына, тарихына, гореф – гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту;

-Үз халкы белән горурлану хисе тәрбияләү;

-Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын булдыру;

- Иҗат итү омтылышы уяту.

Куелган бурычларны чишү өчен түбәндәге методлар комплексы кулланыла:

Теоретик (фәлсәфи, фәнни, методик әдәбиятны анализлау)

Эмперик (әңгәмәләр, төрле темаларга сораштырулар,эзләнү – тикшеренү эшләре, алдынгы тәҗрибәләрне гомумиләштерү)

Тарих дәресләрендә җирле материаллардан файдалану укучыларда туган җирләренә, туган халкына мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә мөһим чара булып тора. Үзеңнең туган төбәгең мәктәбендә укыту җирле материаллардан файдалану мөмкинлеген, әлбәттә, күбрәк бирә, чөнки үзең кечкенәдән барысын да күреп, ишетеп үсәсең, ул тарих сиңа якын.

Җирле материаллар туплауны мин мондый юнәлешләрдә алып барам:

1. Безнең төбәктә табылган матди тарихи чыганакларны туплау;
2. Төбәгебезнең тарихи сәхифәләрен билгеле бер системага салу;
3. Безнең төбәктән чыккан мәгрифәтчеләрнең тормыш юлларын һәм фәнни-педагогик эшчәнлекләрен тикшерү.

Татар халкы тарихы үзенең тамырлары белән ерак чорларга барып тоташа. Безнең Арча төбәге тарихы да шушы чал тарихның аерылгысыз бер

өлеше. Әлеге җирләр борынгы заманнардан ук фин-угор кабиләләре тарафыннан үзләштерелә башлаган. Бу турыда шул чор кешеләреннән калган матди культура калдыклары дәлилли. Шулай да бу җирләр актив рәвештә Казан ханлыгы чорында үзләштерелгән.

7 һәм 10 сыйныфларда Татарстан һәм татар халкы тарихының XVI уртасы - XIX гасырларга караган чорын өйрәнгәндә, мин үзебез төбәккә туры килгән өстәмә материалларны кулланырга тырышам. Бу Казан ханлыгының Иван Грозный тарафыннан яуланып алынуы һәм безнең төбәктә чукындыру сәясәтен алып бару. 1552 елдан безне 473 ел аерып тора. Шушы еллар эчендә татар халкы үзенең милләтен, телен, мәдәниятен, динен саклап калу өчен көрәшә, һәм бу көрәштә Арча ягы халкының роле бик зур. Төп максат: Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яуланып алынганнан соң дәүләтнең мөселманнарга карата дини сәясәтен өйрәнү һәм анализлау, Арча төбәгендә бу сәясәтнең ничек алып барылуын ачыклау.

Шушы максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куела: мөселманнарга карата Россия дәүләтенең төп дини сәясәте юнәлешләрен ачыклау; Казан ханлыгы яулап алынганнан соң мөселманнарның дини ирек өчен көрәшен анализлау; миссионерлык эшчәнлеге үсешен өйрәнү; үзебезнең якын-тирә авыл халкының чукындыру сәясәтенә каршы көрәшен чагылдыру.

Эзләнү эшен алып бару вакытында укучылар күп кенә тарихи әдәбият, архив материаллары, газета-журнал мәкаләләре белән танышты һәм авылларыбыз тарихына караган риваятьләр белде. Бу эшне башкарганда безгә Әдәбият музееның элеккеге директоры Фазлыйахметов Ринат абый һәм Арча шәһәренең “Туган якны өйрәнү” музее коллективы булышты. Шушы чыганаклар буенча Арча төбәге халкының XVI гасырның икенче яртысыннан XIX гасыр ахырына кадәр вакыт эчендә дини көрәшен өйрәндек.

Казан ханлыгының бер өлкәсе буларак, Арча кенәзлеге Мәскәүгә каршы сугышта актив катнаша. Ул Казанга гаскәр, сугыш кирәк-яраклары җибәрә, 1552 елның җәендә кенәзләр (әмирләр) Япанчы һәм Явуш җитәкчелегендә

сугыш хәрәкәтләре оештыра. Соңгылары исә Казан янында торган рус гаскәрләренә җитди һөҗүмнәр ясыйлар. Рус гаскәрләре, арчалыларның Казанга ярдәмгә килүен тоткарлау өчен, Арча кырында махсус манаралар корырга булалар. 1552 елның 30 августында дошман, Япанчы һәм Явуш гаскәрләрен алдап, засадага кертә һәм "татарларны кыралар".

Арча-Казан арасындагы авылларның байлыгы турында А.Курбский шаккатып яза. "Бер авылны да калдырмадык, яндырдык, байлыгын таладык, халкын әсир итеп алдык", - дип яза ул мактанып.

Казан дәүләтен яулауның беренче көннәреннән үк патша хөкүмәте Урта Идел буйларында яшәгән рус булмаган халыкларны тулысынча христианлаштыру сәясәте алып бара. Бу түбәндәге максатлардан чыгып эшләнә:

- руслаштыру, ягъни җирле халык арасында рус телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, православие динен көчләп тагу;
- Урта Идел халыкларының милли бердәмлеген какшату;
- йомышлы татарлар арасында Рус дәүләтенә хезмәт иткән катлау барлыкка китерү. Ул чорда дин әхлак һәм хокук нигезе генә түгел, дәүләт идеологиясен дә тәшкил итә.

Христианлаштыру түбәндәге методлар белән кертелә:

1. Мәҗбүр итү методы:- мәчетләрне җимерү;
2. Чукындыруга каршы килгәннәрне төрмәгә утырту, үтерү.
3. Чиркәү учреждениеләре системасы булдыру:

- 1555 елда Казан епархиясе төзелә ( Гурий)

- Чиркәү һәм монастырьлар төзү;

3. Икътисади яктан басым ясау:

- чукындырылган крестьяннарның бер өлеш ясакларын чукынмаган крестьяннардан түләтү.

- Җир биләмәләрен чукындырылмаган туганнарга бирүне тыю.

Христианлаштыру ысуллары:

- Яңа дингә “ иркәләп һәм яратып” кертү; православие динен кабул итүчеләргә өстенлекләр һәм ташламалар куллану.

- XVII гасырда христианлаштыру сәясәте мәҗбүр итү юлын сайлый.

- XVIII гасырның икенче яртысында христианлаштыру сәясәте кырыслана.

Христианлаштыру шаукымы Арча ягы халкын да читләтеп узмаган. 1555 елларда көчәеп китеп 1600 елларга Җөри һәм Арча юлындагы 24 татар авылының 19 чукындырылганы билгеле. (Арча хәбәрләре”, 2011 № 9-10).1565 – 1568 елларга караган чыганакта ук инде Чүриле ( хәзерге Иске Чүриле) авылының татарлардан торган халкы керәшеннәр ( урысча “Новокрещен”) дип күрсәтелә. 1602 – 1603 елларда бу “яңа чукынган” авылда 5 йомышлы кеше һәм 13 ясаклы кеше хуҗалыгы исәпләнә. XVII гасыр башында Арча ягының Апаз, Әзәк, Кишмәт, Яңасала, Курса авыллары халкы да “яңа чукынганнар” рәтендә йөргән. Әзәк авылында, мәсәлән, ул вакытта йомышлы керәшен Василий Андреевтан тыш биш йорт ясаклы керәшеннәр дә яшәгән.

Халык телендә бүген дә түбәндәге риваять яши: “Югары Әзәк һәм Иске Иябаш авыллары арасындагы басуда коры елга, икенче төрле “Кан елгасы “ дип йөртелгән елга бар. Чукындыру отрядлары Әзәк авылына килеп чыгалар һәм авыл халкын шушы елгага куып кертәләр. Башта тыныч юл белән кызыксындыру хисабына күп нәрсә вәгъдә итәләр, тик халык алданмый. Аннары куркытып, төрле ысуллар кулланалар. Нәтиҗә булмагач, мәҗбүри көчләп-үтереп, кыйнап чукындыруга күчәләр. Әзәк авылы халкы һәм тирә-як авылы кешеләре бик нык каршылык күрсәтә. Ләкин көрәк, сәнәк белән генә коралланган халык бик тиз җиңелә. Кеше кырыла, мәетләр белән тулган елгадан кеше каны ага. Менә өч гасырдан артык инде бу елганы “Кан елгасы” дип атап йөртәләр. Исән калганнар гомерләрен, балаларын саклап калу хисабына чукынырга мәҗбүр булалар. Шулай да чукындырылган халыкның бик күбесе , яшерен генә булса да, ислам динен тоткан. Ачыктан-ачык кире исламга кайтучыларны таяклар белән суктырганнар, төрлечә мәсхәрәләгәннәр. Яңа чукынучыларны карап тикшереп тору өчен 10 йортка

бер рус гаиләсен китереп урнаштырганнар”. Кайсыбер авыллар шушындый ысул белән тулысынча христианлашып беткән. Мәсәлән, Иске Чүриле авылы.

Иске Иябаш авылы кырындагы урман полосасы янында Казан ханлыгы чорыннан калган зират урыны бар. Бу урынны Изгеләр зираты дип йөртәләр. Анда барлыгы биш кабер ташының ватыклары саклана. Бер ташның куелу вакыты 1528 елларга туры килә. Бәлки бу урында Казан ханлыгы чорына караган 7 мәчетле зур Миһербан авылы булгандыр. Ханлык җимерелгәч, бу авыл туздырылган. А.Курбский да үзенең язмаларында , бу авыл таркалгач, аннан ике Иябаш авылы оешкан, тагын күп кешеләр Әзәк авылларына да күчеп утырганнар, дип язып калдырган.

Иске Иябаш авылы янында көчләп чукындыручыларның бер отрядын кырып бетерәләр. Шуннан соң руслар татарлардан 334 кешене тотып алып үзләренә чокыр казытканнар һәм аларны тереләй җиргә күмгәннәр дип сөйлиләр. Бу урынга урман хуҗалыгы картасында “Туганнар кабере” дип тамга төшерелгән.

Хәзерге Иске Кырлай авылы урынында булган авыл чукынмый кала. Авыл халкы чукындыру өчен килгән отрядка бер көтү мал җыеп биреп котыла. Ләкин күпмедер вакыттан соң килгән икенче бер отряд белән бәрелешләр булгач, авыл халкы бу урынны ташлап китә. Авылның исеме онытылган, фәкать шушы Миһербан авылы кешеләре белән бәйле авыл булмадымы икән дигән риваятьләр бар.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, Иске Иябашыннан чукынырга теләмәгән кешеләр һәм Александровка авылы урынындагы татар авылыннан 4-5 хуҗалык Яңа Иябашы авылына күчеп килгәннәр.

Иске Иябаш авылы халкы 1742 елда көчләп чукындырыла, 1871 елларда кире ислам диненә кайта. Әзәк авылының кире ата-баба диненә кайтуы 1870 елларга туры килә. Авылда 83 йортта керәшенлектән яңадан исламга күчкән 195 ир-ат һәм 216 хатын-кыз яшәгән. Түбән Әзәктә 44 йорт булып, мөселманлыкка кайткан 97 ир-ат һәм 101 хатын-кыз яшәгән. 1900 елларда Югары Әзәктә 495, Түбән Әзәктә 325 кеше татар буларак теркәлгән.

Д.А.Корсаков җыентыгында Иске Иябаш авылында 60 керәшен татары яшәвен күрсәтелә. Бу авыл халкы да күптән инде кире мөселманлыкка кайткан ( Сборник 1908, 258). Иске Иябаш авылы Н.А.Износков хезмәтендә түбәндәгечә сыйфатлана. Авыл Ия суы буена, Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан. Авылда 62 хуҗалык булып, анда керәшенлекләрен ташлап яңадан мөселманлыкка кайткан 171 ир-ат һәм 185 хатын-кыз яшәгән. Авыл халкының тормышы уртача булган. Халык тегүчелек һәм киндер сугу белән шөгыльләнгән. Вәрәнгуш-Иябаш авылындагы 101 хуҗалыкта мөселман дине тотучы 277 ир-ат һәм 308 хатын-кыз яшәгән, тормышлары уртача булган. Авылда умартачылык, киндер туку белән шөгыльләнгәннәр.( Список 1885, 16, 4-5, 7-8).

Танылган галимебез, тарихчы М.Әхмәтҗанов әйтүенчә, Әзәк авылы халкына кире исламга кайтуда Олы Мәңгәр авылы кешеләре зур булышлык иткәннәр. Алар Казандагы зур урыс түрәләре белән сөйләшүләр алып барганнар һәм акчалата да булышканнар. Инде килеп Совет чорында , мәчет манаралары киселгән вакытларда Әзәк авылы халкы мәчетне һәм манараны саклап кала алган.( Фәрит Салих.”Арча хәбәрләре” 2011 №9-10- Мәкаләне язганда автор Татарстан милли архивында саклануччы рәсми мәгълүматлардан файдаланды).

Арча төбәгенең бай тарихы, әлеге җирлектә туган һәм буыннан буынга туплана килгән рухи мирасы бар. Болгар, Алтын Урда, бигрәк тә Казан ханлыгы чорында Арча милли дәүләтчелекнең төп терәкләреннән берсе булган. Төбәгебез хәзерге чорда да үзенең лаеклы урынын саклый.

Казанышлар һәм югалтулар белән сыналган хакыйкать: үткәнне белмичә торып киләчәкне корып булмый. Без халкыбыз туплаган бай мирасны һәм тәҗрибәне тирәнтен өйрәнгәндә генә асылыбызга кайта алачакбыз.

Бу эзләнү эше белән шөгыльләнгәннән соң без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

Арча төбәге элек-электән милли дәүләтчелегебезнең төп терәкләреннән берсе булган.

Иван Грозный Казанны тар-мар иткәннән соң күп кенә данлыклы шәхесләр Арча ягында сыену урыны тапканнар.

Арча ягы халкы беренчеләрдән булып 1553-1557 елларда милли - азатлык хәрәкәтен башлап җибәрәләр.

Дини изүгә төрле юллар белән каршылык күрсәтәләр.

Халык күңелендә тарихның бу чоры риваятьләр, легендалар булып бүген дә саклана.

Йомгаклап шуны әйтергә була: туган як турындагы материалларны дәрестә һәм сыйныфтан тыш чараларда куллану укучының дөньяга карашын киңәйтә, туып-үскән төбәге белән кызыксынуын арттыра, кече ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияли. Җирле материалларны кулланганда, бары тик дәреслек буенча гына уздырганга караганда, дәрес күпкә җанлырак, активрак, кызыклырак уза. Программа материалы да җиңелрәк үзләштерелә, хәтергә яхшырак уелып кала. 5-6 сыйныфларда укучылар гаилә шәҗәрәләрен төзеде, бәйрәм проектлары, рефератлар әзерләде. X сыйныфта укучылар районыбыз, авылларыбыз тарихын, күренекле шәхесләрне, 1930 – 50 елларда репрессияләнгән якташларыбызны барладылар. XI сыйныфта туган як тарихы комплекслы өйрәнелә, республика тарихына аеруча игътибар бирелә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: Әнвәр Хуҗиәхмәтов әйткәнчә, тәрбия һәм белем бирү кебек төшенчәләрне аерып карау шулай ук дөрес түгел. Бу – бердәм процесс булырга тиеш. Укыту-тәрбия процессында региональ компонент һәр дәрестә, һәр тәрбия чарасында билгеле бер программа нигезендә системалы алып барылганда гына, укучыларда милли үзаң, аларны милли рухлы итеп тәрбияләргә мөмкин. Халкыбыз, аның мәдәнияте, мәгарифе тарихын, әдәбиятын, тел үзенчәлекләрен, туган якны җентекләп өйрәнгәндә генә, дөнья тарихын, мәдәниятен, мәгарифен тирәнтен үзләштерергә була.

Файдаланылган әдәбият

1.Арча төбәге тарихы.-Казан: Татарстан кит. нәшрияты, 1996.-256б.

2.Атлас Tartarika. История татар и народов Евразии. Республика Татарстан вчера и сегодня: справочно-энциклопедическое изд.- М.: Дизайн. Информация. Картография,2006.888с.

3. Гарипова Ф.Р. Авыллар һәм калалар тарихыннан. Беренче җилд.- К.:”Матбугат йорты”нәшр., 2001.

4. Документальный сборник “Источники по истории Татарстана(XVI-XVIIIвв.)”- 2я кн. Автор-сост: Алишев С.Х., ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АНТ, 1994.

5. Исхаков Р.Р. Мисионерство и мусульмане Волго-Камья (последняя треть.

XVIII-н. XX в.)-Казан: Татар.кн.изд-во, 2011.-222с.

6. Ислаев Фәйзелхак Миссионерлык турындагы китап

7. Әзәк авылы.//Арча хәбәрләре 2011, №9-10.

8. Казанский поход.// Арский вестник. 1997, 15 окт.

9. Хузиахметов А.Н. Воспитание личности школьника: учебно-методическое пособие. - Казань.: Изд-во «Матбигат Йорты»,-1999.-224с.

10. Хузиахметов А.Н. Педагогика: Введение в педагогическую деятельность: Краткий конспект лекций / А.Н. Хузиахметов; Казанский (Приволжский) федеральный университет. – Казань, 2013. – 112 с.

## НРАВСТВЕННО-ПАТРИОТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ В ДЕТСКОМ САДУ

***Сабирзянова Э.Р.***
*воспитатель г. Кукмор, «Детский сад №9 «Рябинушка»,РТ*
***Тимергалиева А.М.***
*воспитатель г. Кукмор, «Детский сад №9 «Рябинушка»,РТ*

Патриотическое воспитание составляет одно из важных направлений государственной политики в образовании. Ребёнок не рождается патриотом, он им становится.

Патриотическое воспитание — одна из актуальных проблем, которая должна решаться сегодня всеми нами, кто имеет отношение к детям.

Важно донести до сознания воспитанников образы, воспитывающие мужество, смелость, героизм, самоотверженность, воспитывать уважение к государственной символике, любовь к родному городу, краю, Родине.

Мировоззрение педагогов, родителей, их личный пример, активная жизненная позиция, взгляды, суждения – самые сильнодействующие факторы воспитания. Важно, чтобы ребенок уже в дошкольном возрасте почувствовал причастность к своей Родине, личную ответственность за родную землю и ее будущее.

Формирование патриотических чувств детей дошкольного возраста осуществляется в процессе использования различных форм и методов работы: занятия, праздники и досуги, подвижные и дидактические игры, эстафеты.

Одной из полюбившейся традицией стало еженедельное торжественное поднятие флага Российской Федерации и Республики Татарстан, а также прослушивание гимна РФ и РТ. Данное мероприятие проводится с целью привития детям чувства патриотизма, уважения к государственному символу и гордости за свою страну.

Наибольший воспитательный эффект оказывают массовые спортивные праздники и развлечения: Весёлые старты, Неделя здоровья, А ну-ка, мальчики, Будем в Армии служить! Первые шаги к ГТО, День Победы, Туристические прогулки по родным местам и памятникам и т.д. Данная форма работы позволяет закрепить и обобщить знания и умения детей в рамках определённой темы, объединить детей общими чувствами и переживаниями. Через соревнование ребенок формирует собственное представление о своих возможностях, самоутверждается, приобретает уверенность в своих силах.

На физкультурных занятиях применяют строевые упражнения. Строевые упражнения являются хорошим средством формирования правильной осанки, воспитания дисциплинированности, готовности быстро и четко выполнять команды и распоряжения; развивают навыки

пространственной ориентировки, глазомер, быстроту реакции и других ценных качеств, необходимые будущим защитникам Родины.

Одним из эффективных средств формирования патриотизма является подвижная игра. Подвижные игры просты в организации, всегда интересны детям и эффективны как для физического развития, так и социального и интеллектуального.

Неотъемлемой частью нравственно-патриотического воспитания дошкольников являются подвижные народные игры. Знакомить детей с русской народной подвижной игрой можно начинать ещё с младшего дошкольного возраста. Важно заострить внимание детей к игре, привить желание играть.

В народных играх много юмора, соревновательного задора, движения точны и образны, часто сопровождаются неожиданными моментами, любимыми детьми считалками. Используя народные игры в учебно-воспитательном процессе, рассказываем детям о жизни того народа, в чью игру им предстоит играть, показываем иллюстрации, отражающие культуру народа, предметы быта и искусства. Для детей интересны игры, отражающие традиционные обычаи народа: Золотые ворота, Гуси-лебеди, У медведя во бору, Зайка беленький сидит и ушами шевелит…, Пузырь… и т.д.

Большая роль отводится наглядно-дидактическим пособиям. Дидактические игры можно использовать и воспитателю, и логопеду во время занятий фрагментарно, подбирая подходящие материалы, а так же в режимных моментах.

Как развивать в ребенке навыки мышления? Какие приемы и технологии использовать? Один из популярных приемов игровой технологии, разработанных американским ученым и психологом Бенджамином Блумом. Прием называется "Кубик Блума". Предложенная им теория обозначена блоками "Знаю", "Творю" и "Умею". То есть, ребенку предлагают не готовое знание, а проблему. А он, используя свой опыт и познания, должен найти пути разрешения этой проблемы. "Кубик Блума" уникален тем, что позволяет

формулировать вопросы самого разного характера. Оборудование: кубики, на гранях которого написано: Назови. Почему. Объясни. Предложи. Придумай. Поделись.

Педагог или один воспитанник бросает кубик. Выпавшая грань укажет: какого типа вопрос следует задать. Удобнее ориентироваться по слову на грани кубика - с него и должен начинаться вопрос.

Назови. Предполагает воспроизведение знаний. Это самые простые вопросы. Ребенку предлагается просто назвать предмет, явление, термин, действие и т.д.

Почему. Это блок вопросов позволяет сформулировать причинно-следственные связи, то есть описать процессы, которые происходят с указанным предметом, явлением.

Объясни. Это вопросы уточняющие. Они помогают увидеть проблему в разных аспектах и сфокусировать внимание на всех сторонах заданной проблемы.

Предложи. Ребенок должен предложить свою задачу, которая позволяет применить то или иное правило. Либо предложить свое видение проблемы, свои идеи. То есть, ребенок должен объяснить, как использовать то или иное знание на практике, для решения конкретных ситуаций.

Придумай. Это вопросы творческие, которые содержат в себе элемент предположения, вымысла.

Поделись. Вопросы этого блока предназначены для активации мыслительной деятельности дошкольников, учат их анализировать, выделять факты и следствия.

«Кубик Блума» можно использовать на всех этапах занятия любого типа. Однако наиболее удобно применять приём на обобщающих занятиях, когда у ребят уже есть представление о сути темы.

Что касается использования на более раннем этапе изучения блока материала, то в этом случае работу с кубиком можно сделать групповой, то есть ответы на вопросы детям нужно будет формулировать вместе. Этот

упрощённый способ помогает не только «собрать в кучку» все знания детей, но и развить в ребятах чувство коллективизма, необходимости помогать друг другу.

Дидактическая игра «Теневое лото». Развивает у детей внимательность, наблюдательность, логическое мышление, учит находить предметы по тени и сопоставлять их. В игре принимают участие от 1 до 6 детей. Ведущий раздает участникам игры большие карты, а маленькие карточки перемешивает между собой и по одной показывает детям. Ребята должны определить принадлежность предмета, аргументировать свой ответ. Ребенок, ответивший правильно, получает маленькую карточку и закрывает ею пустой квадрат на большой карте. Игра должна продолжаться до тех пор, пока все маленькие карточки не закроют свои тени.

Дыхательные игры «Россия». Правильное речевое дыхание необходимо для развития речи, поскольку дыхательная система - это не что иное, как энергетическая база для речевой системы. Дыхание влияет на звукопроизношение, артикуляцию и голос. Поэтому очень важно развивать речевое дыхание с младшего возраста. Дыхательная игра «Россия» поможет в интересной, игровой форме развивать воздушную струю у детей. Эти игры способствуют: развитию дифференцированного дыхания; более длинному, плавному и ровному выдоху; активизируют губные мышцы, что помогает добиться хороших результатов в процессе исправления речи детей. Вдох через нос, выдох через рот. Дуем на поддувалочки. При проведении игр направленных на развитие у ребенка дыхания, необходимо знать и помнить, что дыхательные упражнения быстро утомляют его и при этом могут вызвать головокружение. Поэтому игры должны ограничиваться по времени 3-5 минут с перерывами на отдых.

Круги Луллия «Символы России». При повороте кругов стрелка выделяет определенные сектора на каждом уровне. На секторах нанесены рисунки, загадки. Игрок задает вопрос и раскручивает игрушку. Полученную

комбинацию можно истолковать как ответ на вопрос, а для расшифровки подключают воображение и логику.

В заключении хотелось бы отметить, что Патриотизм – это естественное чувство, которое заставляет человека любить свою Родину и быть готовым жертвовать ради неё собственными интересами. Становление личности ребёнка происходит через осознание своей сопричастности семье, детскому саду, городу, народу, своей Родине. Чувство сопричастности и есть основа будущего патриотизма.

Литература

Литвинова М. Ф. Русские народные подвижные игры – Просвещение, Москва, 1986

Филиппова С. О. Спутник руководителя физического воспитания дошкольного учреждения - Детство-Пресс, Москва, 2011 – 416 с.

Инструктор по физкультуре - № 2, 2012; № 5, № 8 2015

## ҮСЕП КИЛҮЧЕ ЯШЬ БУЫНГА БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ БИРҮ ЧЫГАНАКЛАРЫ

***Искәндәрова В. В.***
*югары категорияле тәрбияче*
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*“ Арча 10 нчы балалар бакчасы”*
***Хәсәнова А. Д.***
*беренче категорияле тәрбияче*
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*“ Арча 10 нчы балалар бакчасы*

“Бала дөньяга килгәндә ярдәмгә мохтаҗ һәм җентекләп карауны сорый. Ул үзен тәрбияли торган олы кешеләр ярдәмендә физик яктан тиз үсә, аның нервлар системасы үсә һәм камилләшә бара”- ди Әнвәр Нуриәхмәт улы. Бүгенге көндә , Татарстанда һәм башка республикада ,өлкәдә татар мәктәпләрен, балалар бакчаларын торгызу ,яшь буынны халкыбызның рухи һәм мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү җитди бурычка әверелде.Балалар бакчаларында укыту-тәрбия эшен камилләштерү максаты белән халык

педагогикасы хәзинәләреннән файдалану кирәклеге дә көн тәртибенә килеп басты. Яшь буында милли үз аң формалаштыру һәм шуның аша үз туган телен , халкын сөюче , үз милләтенең мәнфәгатьләре өчен янып-көеп йорергә сәләтле шәхес тәрбияләүне халык педагогикасыннан башка күз алдына китерүедә мөмкин түгел. Яшь буынны тәрбияләүдә гореф-гадәтләребезне, традицияләребезне торгызу,яңарту чоры килеп җитте.

Һәр халыкның хәтер сандыгына бала тәрбияләү белән бәйләнешле карашлары,фикерләре һәм ысуллары тупланып килгән,буыннан-буынга тапшырылган. Яңа буын үз чиратында халык меңәр ел туплаган гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап,телен,динен хөрмәтләп яшәгән.Олыга-олы диеп,кечегә-кече дип караган. Картайган ата-анасын тәрбия кылуны,тудырган баласын үстерүне изге бурычы итеп караган,кешенең рәнҗешеннән, каргышыннан,ананың бәддогасыннан –уттан курыккан кебек курыккан.

Баланың беренче көненнән үк туплаган хәзинәсе - туган теле. Ана сөте белән кергән туган тел аша сабыйда газиз әнкәсенә,әтисенә,әби һәм бабасына

туганнарына, туган туфрагына, кош-кортларга,гомумән,тереклек дөньясына мәхәббәт аны белергә,төшенергә омтылу хисләре дә тәрбияләнә.

Безнең әби-бабаларыбыз,тел һәм әдәбият гыйлемнәрен белмәсәләр дә, бала сөйләмендә чит - ят сүзләр буталып йөргәнен яратмаган,татарның татар белән сөйләшүен дә татарча сөйләшергә таләп иткән.

3яшьтән алып 7 яшькә кадәр без балаларны бу “мәктәпкәчә яшьтәге бала” дип атыйбыз, ә аларның яшен-“ мәктәпкәчә яшь” дибез. Кеше шәхесенең үсешендә һәм формалашуында бу яшь бик әһәмиятле чор булып тора. Мәктәпкәчә яшьтә бала организмыныңтагын да ныгыуына һәм үсүенә, шулай ук аның акыл, мораль һәм эстетик тәрбиясенә җитди әһәмият бирелә. Шулай итеп, шушы чорда ук инде тәрбиянең гомуми максаты – шәхеснең бөтен яктан үсеше –ирешә алырлык формаларда җитди һә планлы рәвештә тормыфшка ашырыла башлана. Бу сүзләрне Ә.Н.Хуҗиәхмәтов үзенең “Тәрбия чаралары” китабында аңлатып китә.

Бала үскән саен тәрбия чараларының да саны арта, төрләре үзгәрә. Бала чакта гаҗәеп кызыклы ,тылсымлы ,гыйбрәтле тормыш дәреслеге бар. Бу-әкиятләр. Аларга халыкның педагогик культурасы,әхлак сыйфатлары, күңел

матурлыгы тупланган.Аларның һәрберсе гыйбрәтле,үгет-нәсихәтле. Әкиятләрнең тыныч, матур эчтәлеклесе гадәттә йокы алдыннан сөйләнә. Әкият гаиләне бергә,үзара дус итү,өлкәннәрнең һәм балаларның

үзара рухи якынлыгын тәэмин итә.

Үсеп килүче яшь буынга тәрбия биргәндә халык мәкаль һәм әйтемнәрдән файдаланган. Алар халыкның тормыш-көнкүреш тәрбия тәҗрибәсе,

миллионлаган кешеләрнең туганнар,буыннан - буынга күчеп килгәннәр. Мәкаль һәм әйтемнәр кыска,аз сүзле һәм тирән мәгънәле,үгет-нәсихәтле

тиз хәтердә калалар.

Элек-электән телдән-телгә сөйләшеп килгән хикәятләр,кыйссаларның да вәгазьләр,нәсихәтләр тәрбиядә уңай аң урнашуда нигез булып торалар.

Каюм ага Насыйриның баланың холкын,фигылен ихлас итеп, төзәтеп, инсафлы дәрәҗәсенә күтәрү,өйрәтү,укыту,әдәп нигезләре бирү өчен язылган

вәгазьләр,нәсихәтләрен файдалану бик мөһим һәм кирәк.

Бөтен игътибарны балага туплау,тәрбия эшләрен аның туган минутыннан ук башлау,нәни бала табигатенә иң яраклы чаралардан талантлы, комплекслы итеп,баланың һәрьяклап гормоник үсүен тәэмин итәрлеген генә сайлап файдалану халык педагогикасының зирәклеге,кыйммәте турында сөйли.

Һәр ата-ана үзенең баласын тәртипле,гадел,тырыш, тыйнак ,кешелекле итеп күрәсе килә һәм алар үзләренчә шул тәрбияне бирергә тырышалар.

Халык педагогикасында балаларда тугрылык, гаделлек тәрбияләүгә дә зур әһәмият бирелә.

Без, элек, өлкәннәр «яманласаң-телең корыр, урласаң-кулың корыр» дигән куркыныч сүзләр әйтәләр иде.Шулай да сүз-сүз инде ул, иң мөһиме әйләнә-тирәнең, баланы чорнап алган кешеләренә-әти-әнисенә шәхси үрнәк.

Игътибар итеп карасаң, тормышта иң гади һәм иң кирәкле кагыйдәләр-«ярый белән ярамый», «начарбелән яхшы».Ә бит тәрбиянең төп нигезе нәкъ шуларда-халык тәрбиясендә бик күп алымнар кулланыла.

Кыскасы, бала кече яшьтән үк тормышның шушы гап-гади кагыйдәләрен үзләштереп, җанына сеңдереп үссә, киләчәктә әдәп, әхлак кагыйдәләренең һәммәсенә ия була алыр, яхшылыкны начардан аера белер.

Йомгак ясап әйтик, гаилә, балалар бакчалары, мәктәп бу мәсәләгә аеруча зур җаваплылык белән карарга, халык педагогикасын киңрәк файдаланырга бурычлы. Бары тик шул очракта гына милләтебезнең, һәр шәхеснең намуслылыгына, сафлыгына, пакълыгына ирешә алабыз.Тормыш бит ул бер урында гына тормый. Галимнәр яңа ачышлар ясый, инженерлар яңа технологияләр эшләп чыгара, тарих та үзгәрә. Шуңа күрә укыту системасына да үзгәрешләр кертеп тору кирәк.

“Уен кеше тормышында бик әһәмиятле урын тота, ул хезмаәткә хәзерлек булып тора һәм акрынлап хезмәт белән алмаштырылырга тиеш. Күп кенә педагоглар, ата-аналар уенга җитәкчелек итү эшенә тиешле игътибар бирмиләр. Уенның төрле чорларында төрле алымнар кулланырга кирәк, ләкин һәрвакытта да баланың үзешчәнлегенә аның һәм сәләтенең дөрес үсешенә мөмкинлек бирергә, шул ук вакытта кыен очракларда балага булышудан да баш тартмау зарури” – ди “Тәрбия дәресләре” китабында Ә.Н.Хуҗиәхмәтов.

**Кулланылган әдәбият:**


1. К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова “Әхлак нигезе – матур гадәт”. – Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2004.
2. “Балалар бакчасы” Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы – Казан: Раннур, 2003.
3. Ә.Н.Хуҗиәхмәтов “Тәрбия нигезләре”. – Казан , 50-63б, 151-163б.

# ТАТАР ХАТЫН-КЫЗ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ ЭСТЕТИК-ПЕДАГОГИК МИРАСЫН УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА КУЛЛАНУ АЛЫМНАРЫ

***Гайфуллина Л. Х.***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы, МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе» укытучысы*
***Шакирова И.М.***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы, МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе» укытучысы*

Бүгенге көндә заманча мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе - функциональ белемле шәхес формалаштыру. Функциональ грамоталылык терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А. Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: «Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул». Әлеге билгеләмәне гадиләштерсәк, функциональ грамоталылык – кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, тиз җайлашу һәм анда эшләү сәләте.

Функциональ яктан белемле шәхес ул – дөньяда ориентлашкан һәм иҗтимагый кыйммәтләргә, өметләр һәм мәнфәгатьләргә туры китереп эшли торган, сайлау һәм карарлар кабул итү ситуациясендә мөстәкыйль булырга сәләтле кеше. Ягъни безнең бурыч – мәктәп бусагасын атлап чыгышка укучыларыбызны киң эрудицияле, тарихын, бүгенгесен яхшы белгән, үз милләтенең танылган кешеләре турында хәбәрдар, милләте белән горурланып яшәүче белемле шәхес итеп тәрбияләү.

Тарихыбызга күз салсак, татар халкы элек-электән белемгә тартылган, ләкин мәгариф үсеше зур каршылыклар аркылы барган: мәчет-мәдрәсәләрдә күбрәк дини белем бирелгән, зур уку йортларында ир-егетләр генә укыган. Бары XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында татар җәмгыяте зур үзгәрешләр кичерә, мәгърифәтчелек агымы нигезендә дөньяга яңача караш формалаша, тормышны яңача аңлау барлыкка килә башлый.

Белгәнебезчә, мәгариф өлкәсендә зур хезмәт башкарган галимнәребез – мәгърифәтчеләребез шактый: Ш.Мәрҗәни, Г.Курсави, Р.Фәхретдин, Г.Тукай һәм башкалар. Алар турында мәктәп дәреслекләрендә материаллар бар. Мәкаләдә без мәктәп программасына кертелмәгән, Татарстан тарихы дәреслегендә дә телгә алынмаган галимәләребез - татар хатын-кыз мәгърифәтчеләренә тукталырга булдык.

Хатын-кыз мәсьәләсен чишү юлында иң мөһим юнәлеш – ул, әлбәттә, хатын-кыз мәгарифе: татар хатын-кызларына тиешле тәрбия һәм белем бирү, кызлар өчен дөньяви мәктәпләр ачу, мөгаллимәләр җитештерү, тиешле кулланма әдәбият булдыру һ.б., җыеп әйткәндә, баланы замана таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә тәрбияли алырлык ирекле шәхесләр әзерләү бурычы. Гомумән, ике гасыр чигендә «милләт аналары» тәрбияләү мәсьәләсе иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе буларак каралган, чөнки милләтнең киләчәге, иң беренче чиратта, аналар тәрбиясенә бәйле булган.

Казанда беренче җәдит кызлар мәктәбенә 1890 елда мулла һәм мөдәррис Галимҗан Барудиның хатыны Маһруй абыстай Барудия нигез салган. Ул, дини эчтәлекле мәктәп булып калса да, укытуда аваз ысулы куллануы белән башкалардан аерылып торган. Кадими мәктәпләрдә укучылар укырга өйрәнү өчен берничә ел сарыф итсәләр, яңа ысул белән исә алар берничә ай эчендә укырга өйрәнгәннәр [А.Мәхмүтова, 2012: 113].

Бу елларда татар хатын-кызлары үзләре язган әдәби әсәрләре, фәнни хезмәтләре белән дә таныла башлыйлар. Шундыйлардан Галимәтелбәнат Биктимерия, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрия, Фәхрелбәнат Сөләймания, Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова, Маһруй Мозаффария һ.б. бик күпләрне атап үтәргә була. Аларның хезмәтләрендә хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирү, гаилә мөнәсәбәтләре, балалар тәрбиясе, кыз балаларны укыту зарурлыгы, хатын-кызларның бурыч һәм вазифалары һ.б. күп кенә мәсьәләләр күтәрелгән.

Милләт дип җан атып йөргән хатын-кызларыбыз да була бу чорда. Шуларның берсе - рус-татар мәктәбен ачуга ирешкән - Хәдичә Әхмәрова. Ул

Казанның иң бай һәм мәгърифәтле татар хатыннарының берсе булган күп балалы ана. Тарихлары Алтын Урда чорына барып тоташкан борынгы дворян Алкиннар нәселеннән чыккан. XIX гасыр ахырына Алкиннар гаиләсе бай фамилияләр санына гына түгел, ә Казан татар җәмгыятенең интеллектуаль элитасына да кергән.

Казанда мөселманнар өчен дөньяви мәктәпләр булмый. Хәдичә кызы эшли алырлык мәктәп ачуга ирешергә була. Ул вакытта бу рус-татар хатын-кызлар мәктәбе генә була ала. Хәдичә Әхмәрова Казан уку округы идарәсенә дәүләт казнасы хисабына кызлар өчен рус-татар мәктәбе ачуны сорап мөрәҗәгать итә. Казан губернасы халык училищелары директоры Никольский, бу үтенечне “Казан төбәге мөселманнарының, бөтен Россиянең мәгърифәте тарихында куанычлы факт” дип раслап, аның инициативасын хуплый. 1901 елда мәктәп ачуга һәм аның ихтыяҗларына бюджеттан акча бүлеп бирелә. Хәдичә Әхмәрованы әлеге мәктәпнең попечительницасы итеп билгеләнә, аның кызы Маһи-Парвазны да рус телендә дөньяви фәннәр укытучысы итеп билгелиләр.

Хәдичә Әхмәрова үзенә һәм иренә лаеклы, күп көч таләп итә торган эш табуы белән горурлана. Ул мәктәп җитәкчелеген уңышлы үти һәм Казанның иң хөрмәтле хатын-кызларының берсенә әверелә.

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, дәресләрдә хатын-кыз образы белән еш очрашырга туры килә. Әсәрләрдә тугры һәм яратучан йөрәкле, шулай ук кабатланмас күңел матурлыгы белән аерылып торган гүзәл һәм саф хатын-кызларны еш очратасың. Тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтәсе килә: рус әдәбиятында эчке дөньяны һәм хатын-кыз күңеленең катлаулы кичерешләрен сурәтләүгә зур игътибар бирелә. Әсәр укучының күңеленә үтеп керсен, вакыйгалар аңлаешлы булсын өчен дәрес барышында без милли компонент маткриалларын кулланырга тырышабыз.

А.С. Пушкинның “Евгений Онегин” романында төп рольнең берсен алган Таьяна Ларина образын караган вакытта, без аның белемле, итәгатьле, ә инде әсәр азагына дөньяви хатынга әверелүен күзәтәбез.

Укучыларга сорау: “Татар хатын-кызлары арасында белемгә омтылып, җәмгыятьтә үз урынын тапкан хатын-кызлар булганмы?” А.С. Пушкин әсәрендәге Татьяна - финалда көчле, нык, акыллы, зирәк хатын. Аның күңелендә яшьлекнең романтик идеаллары бурыч һәм җаваплылык хисенә урын бирә. Бу образны чын тарихи шәхес Хәдичә Әхмәрова белән чагыштырып, укучылар белән фикер алышып, дәресне җанландырып җибәрергә мөмкин. Табигыйлеген һәм гадилеген саклап кала алган, тормыш авырлыкларына бирешмәгән, җәмгыятьтә лаеклы урын алган бу ике образ – укучыларга тарихи чорны күз алдына китерергә, әдәбиятның нигезендә чын тормыш ятуын исбатларга ярдәм итәр.

Валентин Распутинның “Француз теле дәресләре” исемле хикәясе үзәгендә укучыларны белемле итәргә тырышучы мөгаллимә Лидия Михайловна образы. Район үзәгенә эшкә җибәрелгән яшь кыз һәр укучысын француз теленә өйрәтү өчен бөтен көчен куя, төрле юллар табып, матди яктан да ярдәм итә. Бу очракта да укучылар белән татар мөгаллимәләре турында сүз кузгатып, диалог төзергә була. Өстәмә чыганаклар, җыентыклар ярдәмендә төрле темага проект эшләре, реферат яки фәнни эшләр башкарырга мөмкин.

Класстан тыш вакытта да төрле формада әдәби-тарихи кичәләр, “Могҗизалар кыры”, “Миллион от” кебек мавыктыргыч чаралар аша без укучыларны милли горурлыгыбыз булган шәхесләр белән таныштырырга, тормыш авырлыкларына бирешмәскә, үз максатыңа туры барырга, моның өчен белемгә, шәхси үсешкә ирешергә кирәклекне төшендерергә тиеш.

Инглиз теле дәресләренең “Күренекле шәхесләр” бүлеген өйрәнгәндә, милли-төбәк компоненты буларак, якташ шагыйрьләребез, язучылар турында гына түгел, татар мәгърифәтчеләре хакында да мәгълүмат бирә алабыз. Рус, инглиз һәм татар халыкларының гореф-гадәтләрен, көнкүрешен чагылдырган, тулаем алганда, Россиянең милли-мәдәни колоритын тудырган язмаларга игътибар ителә.

Әйтик, мәгърифәтле татар хатын-кызларының берсе Хәдичә Әхмәрованың тормыш юлы өйрәнгәннән соң, укучылар тарафыннан

иллюстрацияләр ясала, өч телдә тестлар төзелә ала. Өч телдә өйрәтүнең әһәмияте шунда: үзебезнең җирлекнең күренекле шәхесләрен татар теле һәм әдәбияты укытучылары гына түгел, инглиз, рус телчеләре тарафыннан да йогынты ясап, үтемлерәк итеп җиткерергә мөмкин. Күренекле шәхесләр, аларның иҗаты турында белешмәләрне интеграль, билингваль дәресләрдә бирү дә отышлы.

Шулай ук, төрле төбәк, анда яшәүче халыкларның үзенчәлекле яклары белән чагыштырып, укучыларга үз төбәгебезгә генә хас булган кабатланмас рухи байлыкларны төшендерүне, күренекле шәхесләр белән таныштыруны тормышка ашыру өчен, этник-мәдәни компонентны куллану буенча проектлар, буклетлар төзергә мөмкин.

Туган як турында материал куллану төбәгебезнең үзенчәлекләрен тулырак ачыкларга булыша, укучыда горурлану хисе тәрбияләргә мөмкинлек бирә һәм интернет челтәре аша чит илләрдәге дуслары белән хат алышу мөмкинлеген тормышка ашыра.

Монда дидактик характердагы мәсьәләләр дә хәл ителә: индивидуаль эш белән күмәк эш чагылыш таба, педагогик җитәкчелек астында мөстәкыйль эш бара. Чит илләрдәге яшьтәшләре белән хат алышу һәм аларны үзебезнең туган төбәк белән таныштыру диалогик культураны гамәлдә тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Шулай ук, үзебезнең эш тәҗрибәбездә функциональ грамматалылык алымнарына да еш мөрәҗәгать итәбез. Мәсәлән, текстларны анализлаганда, укучыларның танып-белү эшчәнлеген үстерү максатыннан, татар, рус һәм инглиз мәгърифәтчеләре турында мәгълүмати текстларны кулланабыз.

8 сыйныфта “Education” (“Мәгариф”) бүлегендә Бөекбританиянең мәктәп төрләре турында сүз алып барганда Хәдичә Әхмәрова нигез салган кызлар өчен беренче рус-татар мәктәбен мисал итеп китерергә һәм чагыштыру уздырырга була.

Җыеп кына әйткәндә, туган як турындагы материалларны дәрестә һәм сыйныфтан тыш чараларда куллану укучының дөньяга карашын киңәйтә,

туып-үскән төбәге белән кызыксынуын арттыра, кече ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияли. Җирле материалларны кулланганда, бары тик дәреслек буенча гына уздырганга караганда, дәрес күпкә җанлы, кызыклы уза. Программа материалы да җиңелрәк үзләштерелә, хәтергә яхшырак уелып кала.

Мәктәп – кеше тормышының иң гүзәл чоры. Без, укытучылар, белем биреп кенә түгел, балаларны тормыш алып барырга сәләтле итеп тәрбияләргә, алган белемнәрне дөрес юнәлештә файдаланырга өйрәтергә, функциональ грамоталылык формалаштырырга тиеш дип саныйбыз.

Кулланылган әдәбият


1. Вакыт инде, без дә торыйк...( Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашуы: очерклар / А.Мәхмүтова.-Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.-366 б.
2. Мәшһүр татар галимнәре:мәкаләләр, истәлекләр - Казан: Тат.кит.нәшр., 2011.-423б.
3. Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / А.Х.Мәхмүтова.-Казан: Җыен, 2012. – 560 б.
4. Татар энциклопедиясе. / баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2008.-720б.


## ЧЕЛОВЕКА ВЛИЯНИЕ ЗАНЯТИЙ ФИЗИЧЕСКОЙ КУЛЬТУРОЙ И СПОРТОМ НА ВОСПИТАНИЕ ЛИЧНОСТИ СОВРЕМЕННОГО


***Мусина Д. У.***
*учитель физической культуры МБОУ «Школа № 8», Кировского района г. Казань*
***Брагина Э. Д.,***
*ученица 7 «б» класса г. Казань*
*г. Казань, МБОУ «Школа № 8», Кировского района г. Казань*
***Миннибаев Э. Ш.***
*доцент, к.б.н. Казанский федеральный университет г. Казань*


В условиях динамичного и насыщенного вызовами XXI века формирование целостной, гармонично развитой и социально адаптированной личности становится одной из приоритетных задач общества. Современный человек сталкивается с высокими интеллектуальными нагрузками, стрессом, гиподинамией и

необходимостью постоянно адаптироваться к изменениям. В этом контексте систематические занятия физической культурой и спортом выходят далеко за рамки простого поддержания физической формы. Они превращаются в мощный инструмент воспитания, оказывающий комплексное воздействие на все сферы человеческой личности: физическую, психическую, интеллектуальную и социальную.

Актуальность данной темы обусловлена растущей осознанностью в отношении здорового образа жизни, а также потребностью общества в сильных, целеустремленных, дисциплинированных и морально устойчивых гражданах. Целью данной статьи является комплексный анализ влияния занятий физической культурой и спортом на процесс воспитания личности современного человека.

Для достижения этой цели в работе поставлены следующие задачи:

Рассмотреть роль физической активности в физическом развитии и укреплении здоровья.

Проанализировать влияние спорта на формирование волевых и нравственных качеств.

Изучить взаимосвязь физических нагрузок с развитием интеллекта и социальных навыков.

Оценить значение спорта для психического здоровья и профилактики асоциального поведения.

Фундаментом, на котором строится вся личностная структура, является физическое здоровье. Без крепкого здоровья и достаточного уровня физической подготовленности невозможно полноценное функционирование человека в любой другой сфере жизни. Занятия физической культурой и спортом являются наиболее эффективным и естественным способом поддержания и приумножения здоровья.

Регулярные физические нагрузки способствуют укреплению опорно-двигательного аппарата, развитию и укреплению сердечно-

сосудистой и дыхательной систем, нормализации обмена веществ, повышению иммунитета, повышению общей работоспособности.

Таким образом, физическая культура закладывает тот жизненный ресурс, который позволяет личности активно существовать, ставить и достигать долгосрочные цели. Здоровый человек более уверен в себе, оптимистичен и открыт для нового опыта, что является важной предпосылкой для успешного воспитательного процесса.

Спорт по своей сути является мощным инструментом закалки характера. Воспитание волевых качеств происходит через преодоление постоянно возрастающих трудностей, будь то усталость, боль, страх или необходимость выполнить сложное упражнение.

К ключевым волевым качествам, формируемым в спорте, относятся дисциплинированность, целеустремленность, настойчивость и упорство, самообладание и стрессоустойчивость, смелость и решительность.

Параллельно с волей формируется и нравственный стержень личности. Спорт учит таким этическим принципам, как честность и справедливость, уважение, ответственность, толерантность.

Через поражения и победы человек познает ценность труда, учится адекватно оценивать свои силы и уважать чужой успех. Этот опыт бесценен для жизни в современном конкурентном обществе.

Распространенное мнение о том, что спорт и интеллект слабо связаны, является глубоким заблуждением. Современный спорт, особенно командный, требует высокого уровня умственного развития.

Интеллектуальное развитие в спорте проявляется: в тактическом и стратегическом мышлении - спортсмен должен не только быстро бегать или высоко прыгать, но и анализировать ситуацию, предугадывать действия соперника, мгновенно принимать тактические решения; в пространственном мышлении и восприятии - необходимо оценивать расстояния, скорость перемещения объектов (мяча, партнеров,

соперников), траектории; в развитии памяти и внимания - запоминание сложных комбинаций, игровых схем, концентрация на задаче в условиях посторонних раздражителей (крики болельщиков); в самопознании и рефлексии - спортсмен учится анализировать свои сильные и слабые стороны, работать над ошибками, что является важнейшим метакогнитивным навыком.

Не менее значимо влияние спорта на социальное развитие личности. Командные виды спорта – это микромодель общества. Участвуя в них, человек осваивает ключевые социальные компетенции: коммуникативные навыки - умение четко и своевременно доносить информацию до партнеров, понимать невербальные сигналы; командное взаимодействие (teamwork) - способность ставить общие интересы выше личных, доверять другим, координировать свои действия с действиями группы; лидерские качества - в командах естественным образом выявляются лидеры, которые берут на себя ответственность и ведут за собой остальных; умение разрешать конфликты - в любой группе неизбежны трения, и спорт учит конструктивному выходу из конфликтных ситуаций.

Эти навыки абсолютно необходимы современному человеку в любой профессиональной сфере, где преобладает проектная работа и межличностное взаимодействие.

В эпоху информационной перегрузки и хронического стресса значение физической культуры для психического здоровья трудно переоценить. Занятия спортом выступают в роли естественного антидепрессанта и стабилизатора эмоционального состояния.

Психологическое воздействие спорта заключается в следующем:

Снижение стресса и тревожности: во время физической нагрузки в организме выделяются эндорфины («гормоны радости»), которые улучшают настроение и снижают уровень гормонов стресса, таких как кортизол.

Повышение самооценки и уверенности в себе: достижение спортивных результатов, преодоление себя дают человеку ощущение компетентности и силы, что напрямую влияет на его самооценку.

Эмоциональная разрядка: спорт является социально приемлемым способом выплеснуть накопившуюся агрессию и негативные эмоции.

Формирование позитивного мировосприятия: активный образ жизни способствует оптимизму и повышает общий жизненный тонус.

Кроме того, систематические занятия спортом являются мощным средством профилактики асоциального поведения, особенно среди детей и молодежи. Регулярные тренировки:

Организуют досуг, оставляя меньше времени на бесцельное времяпрепровождение и потенциально опасные компании.

Формируют здоровые жизненные ценности и ориентиры, противопоставляя их деструктивным моделям поведения (употребление наркотиков, алкоголя).

Дают чувство принадлежности к группе (спортивной команде, клубу), что удовлетворяет одну из базовых социальных потребностей человека и снижает риск маргинализации.

Таким образом, физическая культура выступает не только как средство воспитания сильной личности, но и как важный социальный институт, способствующий укреплению общественного здоровья и снижению уровня девиаций.

Проведенный анализ позволяет сделать однозначный вывод о том, что занятия физической культурой и спортом оказывают многогранное и глубокое влияние на воспитание личности современного человека. Это влияние выходит далеко за пределы сугубо физического развития и охватывает все ключевые аспекты становления индивида как полноценного члена общества.

От укрепления здоровья и развития физического потенциала, через закалку воли и формирование нравственных принципов, до развития

интеллекта, социальных навыков и поддержания психического равновесия – спорт является универсальным воспитательным инструментом. Он готовит человека к жизни в условиях конкуренции, учит дисциплине, работе в команде, стойкости перед лицом неудач и уважению к себе и другим.

В современном мире, где риски гиподинамии, стресса и социальной разобщенности продолжают расти, ценность систематической физической активности только возрастает. Поэтому популяризация спорта и создание доступной инфраструктуры для занятий физической культурой должны рассматриваться не как второстепенная задача, а как стратегическое направление в области образования, здравоохранения и социальной политики, направленное на воспитание сильного, здорового и гармонично развитого поколения.

Литература


1. Выдрин, В. М. Методические проблемы теории физической культуры / В. М. Выдрин // Теория и практика физической культуры. – 2020. – № 6. – С. 15-18.

2. Лубышева, Л. И. Социология физической культуры и спорта : учебное пособие / Л. И. Лубышева. – 4-е изд., перераб. и доп. – М. : Академия, 2019. – 384 с.

3. Матвеев, Л. П. Теория и методика физической культуры : учебник для ин-тов физ. культуры / Л. П. Матвеев. – 4-е изд., стер. – М. : Физкультура и спорт, 2019. – 543 с.

4. Наталов, Г. Г. Воспитание физических качеств личности в процессе занятий спортом / Г. Г. Наталов. – Краснодар: КГУФКСТ, 2018. – 212 с.

5. Столяров, В. И. Ценности спорта и воспитание молодежи / В. И. Столяров // Спорт, духовные ценности, культура. – М., 2017. – Вып. 8. – С. 20-45.


## ЯШЬ БУЫНДА ВАТАНПӘРВӘРЛЕК СЫЙФАТЛАРЫ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ Ә.Н. ХУҖИӘХМӘТОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ


***Җамалиева А.М.***
*Арча районы Яңа Кишет төп гомуми белем мәктәбе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Җәләлетдинова Г.Р.***

*Арча районы Яңа Кишет төп гомуми белем мәктәбе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкы – кешелек тарихында тирән эз калдырган милләт. Аның бай тарихы, күп гасырлар буена тупланган кыйммәтле матди һәм рухи мәдәнияте, асыл гореф-гадәтләре, традицияләре, күпкырлы педагогикасы бар. Борын-борыннан ук халкыбызның тәрбия тәҗрибәсендә һәм исламда Ватан, халык, ил-җиргә бирелгәнлек, батырлык игътибар үзәгендә булган. Әлеге сыйфатлар кешенең иҗтимагый һәм социаль җитлегүенең бер дәлиле буларак, аеруча әһәмиятле. Бу уңайдан шушы төшенчәләрнең асылын ачыклау халкыбыз тарихында аларның тоткан урынын тасвирлауны күпкә җиңеләйтер һәм аңлаешлы итәр.

Ватан ул – кешенең туган җире; халыкның тарихи үсеш үзенчәлекләре, теле, мәдәнияте, көнкүреше, гореф-гадәтләре һәм традицияләре белән бергә яши торган җире, аның табигате. Ватан – кеше үзе туган һәм шуның гражданины булган ил; туган ил; кешенең туган ягы, туган җире.

Патриот һәм ватанпәрвәрлек (патриотизм) төшенчәләренең асылына төшенү өчен дә аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итү урынлы булыр: “Патриот – үзенең туган җирен, халкын, илен, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше. Ватанпәрвәрлек – патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз иленә, халкына мәхәббәт” [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге,1979:506]. Шулай итеп, ватанпәрвәрлек – үз илеңә, халкыңа, туган телеңә, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә олы мәхәббәт ул. Тик ул еш кына бик авыр, катлаулы каршылыкларны һәм кыенлыкларны, психологик кичерешләрне җиңү белән бәйле. Бу хис “батырлык” төшенчәсе белән аваздаш. Батырлык максатка бирелгәнлекне, аны тормышка ашыруда ныклык күрсәтүне аңлата. Ул үз-үзеңне тота алу, каушап калмау, чыдамлылык, файдалы эшләргә әзер булу, бурычны үтәү кебек сыйфатларны үз эченә ала. Башка халыклардагы кебек үк, татар халкына да хас гүзәл сыйфатлар байтак. Шуларның берсе – батырлык, каһарманлык, Ватанны саклауда һәм хезмәттә үз-үзеңне аямау, фидакарьлек. Чөнки халкыбыз баһадир халык булып оешкан.

Батырлык – милләтебезнең горурланырлык сыйфаты. Халкыбыз беркайчан да Ватанына хыянәт итмәгән; татарларны куркаклыкта, батырлыклары җитмәүдә гаепләү адымына берәүнең дә базганы юк әле.

“Яшьләребезгә патриотик тәрбия бирү, илебезнең киләчәген кайгырту турында күп сөйләнә. Тик бу өлкәдә никадәр генә күп көч куелмасын, патриотик хисне басым ясап, Президент Указлары нигезендә генә булдырып булмый. Бу эшчәнлек бала тугач ук башланырга тиеш”, - ди Россия һәм Татарстанның атказанган укытучысы, педагогик фәннәр докторы, профессор Әнвәр Хуҗиәхмәтов. Галимнең Җинүнең 60 еллыгы уңаеннан язылган “Патриотлар тәрбияләргә!” дип исемләнгән мәкаләсе бүген дә бик актуаль. Быел Җинүнең 80 еллыгын каршыласак та, патриотларга караш үзгәрмәде дип әйтәсе килә.

Үз Ватанының гореф-гадәтләрен белүче, хөрмәт итүче, яратучы чын патриот, киңкырлы шәхес тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итү – бүгенге көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ә чынлыкта, бу мәсьәләләр ничек тормышка ашырыла соң, нинди алымнар кулланыла, шул турыда язып үтик әле.

Югарыда әйтелгәнчә, бала теле ачылганчы ук, иң якын сүзләрнең төшенчәсен аңлап үсәргә тиеш. Алар: “әни, әти, туганнар, гаилә, туган нигез, гореф-гадәтләр, туган авыл, туган җир, ил”ебез кебек сүзләр. Шушы сүзләрнең мәгънәсен дөрес аңлап үскән бала ватанпәрвәр булмый кала алмый. Бу сүзләр аның өчен иң якын, кадерле сүзләргә әйләнә. Ә балалар бакчасы, мәктәп, җәмгыять ул сүзләрнең тирән мәгънәсен тагын да киңәйтергә, аларны сакларга, якларга өйрәнергә ярдәм итүчеләр булып тора. Укучыларга рухи-әхлакый тәрбия бирү, ватанпәрвәрлек, гражданлык хисләре уяту мәсьәләсендә мәктәп һәм укытучыны бернәрсә дә алыштыра алмый. Тарих, тормыш иминлеге нигезләре дәресләре, тематик тәрбия сәгатьләре – болар барысы да гражданлык, ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирүдә үтемле чаралар. Ә инде бу дәресләр музей педагогикасы белән үрелеп барганда аларның тәэсирлеге тагын да арта. Музей тәрбия эшен күрсәтмәлелек белән баетып кына калмый, үткән буыннар тәҗрибәсен бүгенге чынбарлык белән тоташтыручы мөһим

фактор булып тора. Яшь буында Ватаныбызга, аның данлы үткәненә хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре тәрбияләү хакында үзебезнең мәктәп музеебыз эшчәнлеге мисалында күрсәтеп китәсе килә. "Мәктәп музее" төшенчәсе иң беренче чиратта аның урыны түгел, ә үзенчәлеген белдерә. Музейның төп эш юнәлеше нәкъ менә укучыларга, аларны илебезнең чын гражданнары итеп тәрбияләүгә багышлана.Чын патриотлар үстерү өчен милли-төбәк компонентларына таяну да зур нәтиҗәләр бирә ала. Мәсәлән, илебез, җиребез тынычлыгы өчен корбан булган, зур батырлыклар күрсәткән авылдашларны үрнәк итеп күрсәтү, авылдашыбыз Советлар Союзы Герое Гани Биккенәй улы Сафиуллинның Бөек Ватан сугышында үзен чын ватанпәрвәрләрчә тота алуын сөйләү дә зур горурлык хисе уята ала. Болардан тыш уку йортларында программа нигезендә алып барылган төрле очрашулар, әңгәмәләр, квест-уеннар, тематик чаралар уздыру, тимурчылык, волонтерлык эшләре, "Алдынгылар хәрәкәте"ндә катнашулар да бу хисне тагын да ныгыта гына дип саныйбыз.

Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары рухи үсешнең төп шарты буларак, яшь буынга ватанпәрвәрлек һәм гражданлык тәрбиясе бирүне куя. Дөрес, моңа кадәр дә гражданлык һәм ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү, белем бирүнең мөһим максатларының берсе булып торды. Чөнки дәүләт белән аның гражданнары арасында үзара җаваплылык мөнәсәбәтләре булмаган илнең киләчәге була алмый.

2022 елның сентябреннән белем бирү процессына яңалык керү белән башланды. Кайбер яңалыклар патриотик тәрбиягә басым ясаудан гыйбарәт. Мәсәлән, мәгариф учреждениеләрендә уку атнасы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы әләмен күтәрү һәм Россия гимнын башкарудан башлана. Күпчелек мәктәпләрдә әләм күтәрү хокукы иң яхшы, укуда, иҗатта яки спортта зур нәтиҗәләргә ирешкән укучыларга бирелә. Моннан тыш, Россия Мәгариф министрлыгы "Мөһим нәрсә турында сөйләшү" дигән күләмле проектны башлап җибәрде. Хәзер илебезнең барлык мәктәпләрендә балаларны кызыксындырган төрле темаларга багышланган сыйныф

сәгатьләре уза. Төп темалар арасында патриотизм һәм гражданлык тәрбиясе, тарихи белем бирү, әхлак һәм экологик проблемалар булачак. Шулай ук мәктәп тормышы, шәһәрдәге вакыйгалар, Россиядәге һәм дөньядагы вәзгыять турында фикер алышачаклар.

Әдәбият укытучылары өчен, әлбәттә, матур әдәбият та күз уңында тотыла. Яшь буында патриотизм хисе тәрбияләүдә матур әдәбият зур урын алып тора. Бу яктан бигрәк тә Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр бала өчен тәрбияви яктан әһәмиятле. Патриотизмның иң матур үрнәкләре белән Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов кебек әдипләр иҗатында очрашабыз. Мисал өчен, Ф. Кәримнең “Ант”, “Ватаным өчен” шигырьләре, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Үлем уены”, “Гөлсем”, “Партизан хатыны” поэмалары аша туган җир, тынычлык, ирек кадерен, яшәү ямен аңлыйлар.[Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе,2005:122].

Тәрбия өлкәсенә аеруча әһәмият биргән, олы хөрмәткә ия булган Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов та “Сез нинди китап укыйсыз?” сәхифәсендә: “Мәгариф өлкәсендә эшләүче кеше буларак, мин балалар әдәбияты белән кызыксынам. Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә торган «Мәктәп китапханәсе» дигән сериягә кергән китапларны укып барам. Кечкенә вакытымнан бирле мөкиббән китеп укыган китабым - Гадел Кутуйның “Рөстәм маҗаралары”. Әлеге фантастик повестьны йөз тапкыр укып чыкканмындыр. Соңгы вакытларда да алып укыдым әле мин аны. Күңелгә кереп калган китапларымның берсе шул. Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр”ен, “Алтын йолдыз”ын бик яратам,-“ дип сөйли. Белүебезчә, әлеге әсәрләр батырлыкны, ватанпәрвәрлекне чагылдыручы матур әдәбият үрнәкләре булып тора.

Нәтиҗәдә, патриотик тәрбия бирүне, әлбәттә башка тәрбияләр: әхлак, экологик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясеннән аерып алып карарга ярамый. Алар комплекслы рәвештә алып барылса гына, гражданлык хисләре тәрбияләүдә уңышка ирешеп була.

Шулай итеп, безнең балаларыбыз инсафлы, тәртипле һәм әдәпле булсын, киләчәктә тормышлары якты, матур, күңел тынычлыгы булсын өчен аларны кечкенәдән үк бу сыйфатларга өйрәтеп үстерү - төп максатларыбызның берсе. Максатларны тормышка ашыру – ата-аналарның һәм педагогларның зур тырышлыкларын таләп итә торган эш. Үз илеңә, туган җиреңә, халкыңа, Ватаныңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә мәхәббәт, матур әдәбият китаплары аша алып барылса, җәмгыятькә лаеклы һәм үрнәк гражданин тәрбияләү бурычын үтәп була.

**Кулланылган әдәбият:**


1.Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2005. – 189 б.

2.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 2 том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1979. –726 б.

3.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001.-221.

4.Чыганак:https://chistopol-rt.ru/news/jemgiyat/mohim-narsa-turynda-soilasu-saxes-formalastyryrga-iardam-ita


## УЧИТЕЛЯ – ФРОНТОВИКИ НЫРТИНСКОЙ СРЕДНЕЙ ШКОЛЫ


***Фахрутдинова Г.И.***

*учитель МБОУ «Ныртинская средняя школа» Кукморского муниципального района РТ*

***Самигуллина Р.М.***

*учитель русского языка и литературыМБОУ «Ныртинская средняя школа» Кукморского муниципального района РТ*


Природа мудра. Она так выстроила путь человеческой жизни, чтобы не ослабевала и не рвалась нить, объединяющая и соединяющая поколения. Храня теплую память о прошлом, мы сохраняем чувства ответственности за Родину, укрепляем веру в силу своего народа, ценность и неповторимость его истории. 2025 год посвящен Году защитника Отечества и 80-летию Великой Победы нашего народа в Великой Отечественной войне. О ней написано немало трудов, издано много монографий и военно-теоретических исследований.

В настоящее время исследования региональной истории приобретают особую актуальность, поскольку, только зная историю своей «малой родины», зная своих ветеранов, можно оценить историю страны.

Для исследования я взяла тему «Учителя - фронтовики Ныртинской средней школы», чтобы на примере судеб учителей села показать, как в их жизни отражена судьба всего многомиллионного народа, какой вклад в разгром фашистской Германии внесли учителя.

В связи со Специальной военной операцией тема патриотизма стала ещё актуальней, я решила провести исследование и посвятить свою работу учителям – фронтовикам, участвовавшим в Великой Отечественной войне, с целью увековечить память о них для молодого поколения.

Я поставила задачу: узнать подробнее о наших замечательных ветеранах, чьи имена многократно повторяются в воспоминаниях выпускников и односельчан.

